Рәфис ШӘЙХӘЙДАРОВ

Балтач мәчетләре

Рәфис Шәйхәйдаров

Балтач мәчетләре

“БАТЫРША”
“БАТЫРША БӘЙЕТЕ”

النظارة الدينية المركزية لمسلمي روسيا — روسيا ... (Arabic letterhead text)

Central Muslim Spiritual Board of Russia
Центральное Духовное Управление Мусульман России

www.cdum.ru

450057, г. Уфа, ул. Тукая,50
тел. (3472) 50-80-86,50-80-79, ф. 50-80-99

129301, г. Москва, ул. Касаткина д. 18 стр. 1
тел. 286-30-94, 286-37-98, ф.283-18-26

04 июня 2010 г. № 215

Бисмилләһир-рахмәнир-рахим.

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Дөньяда яшәвебез – ахирәтнең игенлеге. Ахирәтнең игенлеге шушы дөньябызда яшәгән вакытта игелә. Аллаһның рәхмәтенә таба тоткан юлыбыз белән гомеребез буена йөрергә тиешбез. Һәрбер көнебездә Аллаһ кушканча яши торган булсак, Аллаһ тыелырга кушкан эшләрдән, гөнаһлардан тыела торган булсак, безнең өчен гомеребез бәйрәм булачак.

Кагъбәтулланың бер кисәге булган - Аллаһның йорты мәсҗид-шәрифләр ачылу артканнан арта бара. Мин Балтач районында Аллаһ йортлары ачылу мәҗлесләрендә бик еш һәм шатланып катнаштым. Районда динебезне күңел күзгесе итеп кабул итүләренә чиксез куанам. Аллаһ Раббыбызның бетмәс-төкәнмәс рәхмәт-бәрәкәтләре, һәр ике дөньядагы сәламе җөмләбезгә булып, ошбу йортларга килүләребезне дәвамлы әйләсә иде. Раббым Аллаһ, үзенә сәҗдә кылырга, сәҗдә кыла торган урыннарга йөреп, татулык, бердәмлектә, изге гамәл белән гомерләребезне барчаларыбызга кичерергә насыйп әйләсә иде. Ил-дөньяларыбыз тыныч, тормышларыбыз мул, дәүләтебез имин һәм бәрәкәтле булсын!

Русия мөселманнарының
Үзәк Диния нәзарәте Рәисе, Баш мөфти
Шәйхелислам
Тәлгать Сафа Таҗетдин



Бисмилләһир-рахмәнир-рахим!

Әс-сәламү-галәйкүм вә рахмәтүл-лаһи вә бәрәкәтүһ!

Аллаһы Тәгалә һәрберебезгә үткән гомерләребез турында уйланып, анда булган кимчелек-хаталарыбызны барлап, алардан сакланып һәм пакъланып, калган гомерләребезне игелек һәм Аллаһ ризалыгына лаеклы гамәлләр белән яшәргә насыйп итсен!

Аллаһка булган гыйбадәтне аякка бастыру, гыйбадәтнең мөһимлеген аңлау, язмыш шаяртуларына юлыкканда, хәвеф-хәтәрләр килгәндә генә түгел, һәр вакыт гыйбадәттә булырга, мәчетләргә йөрергә тиешбез.

Динебезне өйрәник, динебез өйрәткәнчә дөнья көтик, гомер итик. Динебезгә хөрмәтебез халкыбызга карата булган хөрмәт һәм сөю кебек олы дәрәҗәгә күтәрелә алсын!

Аллаһы раббил-галәмин хәзрәтләре үз рәхмәте белән дөньяларыбызга тынычлык биреп, Кыяматкә тиклем илебезнең, халкыбызның иминлектә яшәвен насыйп итсен!

Башкортстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе,
мөфти Нурмөхәммәт хәзрәт Нигъматуллин

ХӨРМӘТЛЕ РАЙОНДАШЛАР!

Районда күркәм мәчетләр үз ишекләрен ача. Иман нурына сусаган күңел өчен саекмас чыганакка тиң ул мәчет. Вакыт үтү белән һәркем киләчәк һәм үткәннәр хакында уйлана, тарихи вакыйгаларга игътибарын юнәлтә. Вакыт төшенчәсе акны карадан, хакыйкатьне буш сүздән аерырга ярдәм итә. Нәкъ шул вакыт ата-бабаларыбыздан мирас булып калган ислам дине тормышыбыз маягы булуын ачык күрсәтте. Дин кануннары белән яшәүчеләр хак юлны эзли, үз өстендә эшли, димәк. Тарих җилдавыллары аркасында бихисап мәчетләр, мәдрәсәләр ябылган, манаралар төшерелгән, күпләрнең күңел кыйбласы югалган.

Балтач районында заман шаукымына бирешми сафта калган мәчетләрнең булуы күп нәрсә хакында сөйли, димәк, биредә халык кыйбласын югалтмаган, рухи яктан ныклы булган.

Бүген районда мәчетләр көннән-көн арта бара. Мөмкинлекләре булганнар үз ярдәмнәре белән яңа мәчетләр төзи. Халык иманга илткән юлга тартыла, һәр авыл мәчетенең кичәгесе, бүгенгесе хакында бу китаптагы мәгълүматлардан укып белеп була.

Якты киләчәккә омтылган һәркем кичәгесеннән баш тартмас, үткәннәргә карар, иртәгесен күзаллар. Рухи камиллеккә ирешергә ниятләгәннәр тарих, дин, күңел төшенчәләрен үз итәр. Бу юлда яңа үрләрне үтәргә язсын. Яңа мәчетләр йөрәкләрдә иман нурын өметле илтсен.

БАЛТАЧ МӘЧЕТЛӘРЕ

Шәйхлисламов Нурислам.

Бисмилләһир-рахманир-рахим.

Рухи нигезебезгә кайтуның бер чагылышы булган мәһабәт мәчетләребез белән бүген районыбызның һәрбер төбәгендә сокланырга мөмкин. Алар авылларыбызга ямь өстәп, халкыбызны асылына кайтырга чакырып торалар. Чыннан да, мәчетләребез күзләребезне куандырып, тирә-ягыбызны бизәп торучы корылмалар.

Мәчет (гарәпчәдән «мәсҗид» – сәҗдә кылу урыны) – мөселманнар җыелып, Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылу урыны.

Мәчетләргә кереп гыйбадәт кылган бәндәнең иманы арта, күңеле пакълънә, әхлакый халәте матурлана.

XVIII гасыр ахырында мәчетләр салу өчен урыс патшасы тарафыннан рөхсәт бирелү белән татар дөньясы яңа баскычка күтәрелә. Рухи караңгылыктан яктылыкка чыгу ишеге ачыла. Мәчетләр каршында ачылган мәдрәсәләр тиздән гыйльми мәркәзгә, мәгариф оешмасы үзәгенә әвереләләр. Чыннан да, мәчетләр безнең горурлыгыбыз. Аларда халкыбызның чал тарихы, шатлыгы, хәсрәте, рухи мәдәниятебезнең бай сәхифәләре чагылыш тапкан. Бүген кайбер буш торган мәчетләрне күреп күңел сыкрана. Әгәр алар үзләренең төп вазыйфаларын башкарсалар, җәмгыятебездәге

Зиянгиров Галихан Зиганур улы.

рухи халәт һичшиксез уңай якка үзгәрер, тискәре күренешләр бермә-бер кимер, ата-бабаларыбыз гасырлар буе танып килгән рухи мирасыбыз тормышыбызга яңадан әйләнеп кайтыр иде.

Аллаһы Тәгаләнең мәчетләрен бәндәләр ничек кенә матур итеп салырга тырышсалар да, аларны архитектура ягыннан ничек кенә камилләштерергә, күркәмләштерергә көч куйсалар да, мәчетләрнең зиннәте – ул мәчеткә йөрүче мөселманнар. Аллаһының йортларын яратучы, вакытларын мәчеттә үткәрүче бәндәләр кыямәт көнендә Аллаһының кунаклары булырлар. Аллаһының илчесе: «Бер кавем Аллаһының йортларында җыелышып, Аллаһының китапларын укыса, бер-берсенә өйрәтсәләр, аларның өстенә иминлек килә, алар өстенә тынычлык килә, аларны рәхмәт биләп ала, рәхмәт фәрештәләре өсләренә иңә һәм Аллаһы үз хозурында булган фәрештәләр каршында ул бәндәләрнең исемен искә ала», – дип вәгъдә бирә.

Мәчетләребезнең төп вазыйфасы исә, аларда Аллаһы Тәгаләнең исеме күп зекер ителү. «Мәчетләр – Аллаһы Тәгаләнең исеме күп зекер ителә торган урыннар», – диде галәмнәрнең тәрбиячесе Аллаһы Коръәни Кәримендә. Изге Коръән мәчетләр кору мәсьәләсен дә игътибарсыз калдырмаган: «Аллаһы Тәгаләнең мәчетләрен Аллаһ Сүбхәнәһү вә Тәгаләгә һәм ахирәт көненә иман китергән кешеләр генә кора һәм алар намазны торгызалар, зәкятне түлиләр һәм Аллаһы Тәгаләнең Үзеннән генә куркалар. Бу җәмәгатьнең тугъры юлны табучылардан булуларына өмет бар», – ди Коръәни Кәримнең «Тәүбә» сүрәсенең 18 нче аятендә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтә: «Кем Аллаһының ризалыгын өмет итеп мәчет кора, Аллаһы ул бәндәсенә шул мәчет мисалында җәннәттә йорт салып бирә». Әйе, мәчетләр Аллаһы Тәгаләнең

Сулдан уңга: Ягафәр Садыйк, Балтач муниципаль район хакимияте башлыгы Галләмов Рәфил Әмин улы, Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең Европа өлеше һәм Балтыйк илләренең Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Баш мөфти Тәлгать Сафа улы Таҗетдин, Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Муллагатдәр.

Рамазан бәйреме, 1995 ел.

йортлары. Шуның өчен анда керү дә, чыгу да, эчендә гыйбадәт кылу тәртипләре дә үзе кушканча булу шарт. «Чыннан да, мәчетләр Аллаһы Тәгаләнеке, шуның өчен Аллаһыга тиңләштереп беркемгә дә ялвармагыз», – дигән «Җен» сүрәсенең 18 нче аяте. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәм сәламе булса иде рәсүлебезгә, ул бер Хәдис Шәрифендә әйтә: «Мәчетләребезгә бер яхшы нәрсәне өйрәнү яки аны башкаларга өйрәтү өчен кергән кеше

Аллаһ юлында көрәшүче кебек». Шулай ук пәйгамбәребез (с.г.в.) үзенең хәдисләрендә безгә әйтә: «Берәү мәчеткә бер палас (җәймә) җәйсә, ул кеше өчен җитмеш мең фәрештә истигъфар кыла», «Кем мәчеттән бер кечкенә таш кисәген чыгарса, Аллаһы Тәгалә ул кешенең нәфесеннән зур гөнаһасын чыгарадыр», «Кем мәчеткә ут кабызса, ул кеше өчен фәрештәләр шул мәчеттә яктылык беткәнчегә кадәр истигъфар кылырлар», диелгән.

Башкортстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәммәт Нигъматулла.

Җәмгыятьтә тәртип һәм рухи үсешне тәэмин итүче чыганакларның иң мөһиме – әдәп-әхлак, ә күркәм әхлакның нигезе – дин, иман. Аллаһы Тәгалә кешеләргә туры юлны күрсәткән, хәләлне хәрәмнән аерган һәм аларның чикләрен төгәл билгеләгән. Шул кануннар буенча яшәгәндә генә кеше бәхеткә, уңышка ирешә ала, дөньялыкта тормышы бәрәкәтле, ә ахирәттә киләчәге өметле була. Аллаһы Тәгалә кешеләрне шул кануннар буенча яшәсеннәр, җирдә җәбер-золым кылмасыннар өчен яраткан, үзенең пәйгамбәрләре аша ислам динен җиткергән. Дини кануннарны өйрәнү, шулар буенча гына яшәү һәм аны башкаларга да өйрәтү – һәркемнең бурычы.

Бүген без мәчетләребез хакында сөйләшәбез икән, димәк, безгә изгелеккә, яхшылыкка омтылу, асылыбызга кайту теләге зур, димәк, безгә якты киләчәккә өмет бар. Аллаһы Тәгаләдән шул өметләрне тормышка ашыруда ярдәм сорап калабыз. Аяз күгебездә моңлы азан иртә-кичен яңгырап торсын!

Безнең район авылларында кайсы елда һәм кайсы авылда мәчет төзелүе төгәл мәгълүм түгел. 1930 елга кадәр әлеге Балтач районына кергән авылларда мәчетләр хисабы:

	Авыл исеме	**Мәчет хисабы**
1.	Асавка	1
2.	Бигелде	1
3.	Богдан	5
4.	Зиләзекүл	1
5.	Имән	2

6.	Иске Балтач	2
7.	Иске Илекәй	1
8.	Иске Янбай	1
9.	Иске Яхшый	2
10.	Иштирәк	1
11.	Каргалы	1
12.	Кизгәнбаш	1
13.	Көндәшле	3
14.	Көмьязы	1
15.	Көнтүгеш	2
16.	Мата	1
17.	Мишәр	1
18.	Мәнәгәз	1
19.	Начар	1
20.	Нөркә	2
21.	Солтангол	1
22.	Сәйтәк	3
23.	Текән	1
24.	Тимкә	2
25.	Тузлыкуш	1
26.	Тутагач	1
27.	Тушкыр	3
28.	Тучыбай	1
29.	Түбән Кансөяр	1
30.	Түбән Карыш	3
31.	Түбән Сикияз	2
32.	Уразай	2
33.	Урта-Елга	1
34.	Усман	1
35.	Чишмә	1
36.	Чокалы	1
37.	Чурапан	1
38.	Чуртанлыкүл	1
39.	Чыпчык	1
40.	Шәвъяды	1
41.	Штәнде	1
42.	Югары Кансөяр	1
43.	Югары Карыш	2
44.	Явъязы	1

45.	Ялангач	1
46.	Яңа Балтач	2
47.	Яңа Ямурза	1
48.	Яңа Янбай	1
49.	Яңа Яхшый	1

Җөмләсе 70 мәчет

Җыну көнендә ветераннар белән очрашу.

Авыл мәхәлләсе мәчетләре, гадәттә, бер манаралы булган. Уфа китап нәшриятында 1958 елгы «Башкортстанның архитектура истәлекләре» (16–19 битләр) китабында һәм Казан китап нәшриятында 2007 елда «Русия империясендә ислам институтлары» (277–278 битләр) китабында Иске Тушкыр

авылы мәчете фотосурәте, аның турында мәгълүмат кертелгән. Ул мәгълүматларда Башкортстан Республикасының Балтач районындагы Иске Тушкыр авылы мәчете Идел-Урал төбәгендәге иң беренче төзелгән мәчетләрнең берсе дип әйтелә. Заманында ул галимнәр тарафыннан да өйрәнелгән. Мәчет борыстан төзелгән һәм түбә ябылуы да үзенчәлекле булган. 1891 елга кадәр манаралары булмаган, нәкъ шул елда мәчет яңартылган, ике манара күтәрелгән. «Балтач таңнары» гәзитенең 2010 елның 1 апрель чыккан санында Иске Тушкыр авылы мәчетенең фотосурәте басылып чыккан иде, ә алда искә алган китапларда да нәкъ шул фотосурәт күрсәтелә. Галимнәр эшләгән вакытта авыл халкы алар белән аралашкан, соңыннан да элемтә өзелмәгән, кемдер Уфадан мәчетнең фотосурәтен дә алып кайткан, димәк.

Батырша йорт-музеенда да Иске Тушкыр мәчетенең фотосурәте саклана. Заманында аны Хаблислам Вахитов төшергән (Аллаһының рәхмәтендә булсын). Элек районыбыз авылларында мәчетләр күп булса да, фотосурәтләре бик аз сакланган. Чагыштырмача күптән түгел янган Сәйтәк авылы мәчетенең фотосурәтен зур авырлыклар белән Фәрхәт Габдрахманов ярдәмендә Салават шәһәреннән кайтартылды.

1990 елга кадәр районыбызда бер мәчет – Иске Яхшый авылында гына бар иде. Соңгы 20 ел эчендә тагын 17 Аллаһы йорты үзенең ишекләрен ачты. Бүгенге көндә Бигелде, Богдан, Тутагач, Штәнде, Шәвъяды, Югары Карыш авылларында төзү эшләре, ә Мишәр авылында яңарту эшләре алып барыла.

Әлһәмдүлиллаһ, бүген күп кенә эшмәкәрләр, хакимият органнарында эшләүче җитәкчеләр мәчет төзүдә актив катнаша. Үз хисабларына мәчет төзеткән якташларыбыз да байтак. Шулар арасында: Зиләзекүл авылы мәчетен Хаҗиев Халимулла Ганиәхмәт улы, Чишмә авылы мәчетен Каһиров Илүс Габделхай улы, Илекәй авылы мәчетен Шәйхетдинов Әлфир Бәләгытдин улы, Иске Уразай авылы мәчетен Дилмиев Нурихан Шәмселбаян улы, Түбән Карыш авылы мәчетен Галимов Ринат Нәҗиб улы, Түбән Кансөяр авылы мәчетен Солтанов Әбүлгас Султый улы, Көмьязы авылы мәчетен Хәсәнов Рөстәм Радиф улы, Нөркә авылы мәчетен Низаметдинов Зәниф Зыя улы бу изге эштә күп көч салдылар.

Солтанов Әбүлгас Султый улы фаҗигале рәвештә вафат булды, Аллаһының рәхмәтендә булсын. Үзе вафат булса да, кылган изгелеге онытылмый.

2008 елда Балтач муниципаль район хакимияте башлыгы Галләмов Рәфил Әмин улының башлангычы һәм Балтач районыннан чыккан якташлар оешмасы рәисе Исламов Рәшит Тәрәкый улының ярдәме белән Иске Яхшый мәчетендә яңарту

эшләре башкарылды. Тулаем түбә һәм мәчетнең тышлануы алыштырылды.

Районыбызда үзләренең кылган изгелекләре белән халык теленә кереп калган укымышлы муллалар күп булган. Шуларның берсе – Җиһангир хәзрәт. Ул Иске Штәнде авылында мулла-мөдәррис гаиләсендә туган, авыл мәдрәсәсендә төпле дини гыйлем алган. Үзенең белеме, акылы, шәригать һәм дин кануннарын тирәнтен белүе, шәкертләренә таләпчән һәм гадел булуы белән тирә-яктагы башка муллалар тарафыннан танылган һәм хөрмәт ителгән булган. Хәзрәткә дөньяви һәм дини, әхлаки мәсьәләләр буенча да киңәш сорап килүчеләр өзелмәгән. Җиһангир хәзрәт үзенең белеме һәм шәфкатьлелеге белән халык арасында олы ихтирам яулаган.

Урта Елга авылында яшәүче Нурислам Шәйхлисламов (1916 елгы) шундыйларның берсе. Бик акыллы һәм дини булуы белән башкалардан аерылып тора иде. 1996 елда Зиләзекүл авылында мәчет төзелеп бетеп, намаз укучыларга бирергә вакыт җиткәч, Нурислам бабайның ярдәме әйтеп бетергесез зур булды. Ул вакытта авылда намаз укый белә торган һәм башкаларны да намаз тәртипләренә өйрәтердәй кеше юк иде. Шул вакытта Нурислам бабай 10 көн буе Зиләзекүл авыл халкына намаз тәртипләрен өйрәтеп, үгет-нәсыйхәт кылды, мәчеттә намазлар укыла башлады.

Ялангач авылында Җиһануров Галихан бабай бар иде. Ул 85 яшендә булса да, җомга намазларын Иске Балтач мәчетенә йөреп укыды, ә аена бер тапкыр җомга намазына Уфа мәчетенә бара иде. Көчле иманлы һәм бик гыйлемле кеше булып хәтердә калган. Үзеннән соң өен дә Ялангач авылы халкына мәчет итеп калдырды.

Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәләмнең мондый хәдисе бар: «Шундый көн килер, дин тоту утлы күмер тоту шикелле булыр, тотсаң – пешерер, ташласаң – сүнәр». Шушындый вакытларында да үзләренә читенлек китерә-китерә динебезне безнең көннәргә хәтле алып килеп җиткергән әби-бабаларыбызга Аллаһы Раббыбызның рәхмәте булып, бүген аларга да күңелләребезнең иң түреннәнн чыккан изге хәер-догаларыбыз ирешсә иде.

Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе,
«Батырша» исемендәге Иске Балтач җәмигъ
мәчете имамы Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров.

ИСКЕ БАЛТАЧ ҖӘМИГЪ МӘЧЕТЕ

Иске Балтач авылы мәчете.

Җәмигъ мәчеткә нигез салганда район хакимияте башлыгы Исламов Р.Т. чыгышы. 1993 ел.

«Бар иде заманалар. Аларның котсыз якларын күз алдына китерсәң, күңел тетрәнә, шомлы вакыйгалар хәтергә килә», – дип искә ала Иске Балтач авылы аксакаллары.

Сугышка кадәр район үзәге Иске Балтач авылында ике мәчет була (берсе әлеге Үзәк урамның иске зират урынында һәм икенчесе Кызыл Армия урамында). Икенчесе сугыштан соң сүтелгән, аның урынына өй төзеп чыгалар. Соңгы көненәчә Җамалия Габдулла кызы шунда яшәде (хәзер вафат инде, урыны җәннәттә булсын). Мәчет урынында яшәгәч, даими Коръән укыткан ул...

Үзәк урамдагы мәчетне пыран-зыран китерәләр. Күккә ашкан манарасын бераз кискәч, озын-озын арканнар белән тартып, җиргә аударалар. Бу вәхшилекне җир дә күтәрә алмый, манара аугач, җир тетрәнеп куйгандай була.

Шулай итеп, авылның яме кими, мәчет тәрәзәләреннән бөркелгән илаһи нур сүнеп калгандай тоела.

Яңа мәчет төзелгәнчегә кадәр, дин сабаклары алырга теләге булган кешеләр мөрәҗәгать итүе сәбәпле, 1992 елда дин гыйлеме бирү дәресләре алып барылды. Моның өчен вакытлыча Үзәк урамдагы районның элеккеге киночелтәр бинасы бирелде. Биредә теләге булган йөздән артык мөселманнар – карты һәм яше бик теләп дин дәресләренә йөрде. Укуларны Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров оештырды. Аллаһыга шөкер, бүгенге көндә дә, яңа мәчеттә дин сабакларына өйрәтү дәресләре алып барыла. Әйе, дин нурын халык күңелендә сүндереп булмый, буыннан-буынга күчә килә. Биредә балкып торган яңа мәчет төзелүе дә шул хакта сөйли.

Аллаһы йортына нигез ташы салу 1993 елның июнь аенда үткәрелде. Хәмзә мулла нигез урынына Коръән укыды. Район хакимияте башлыгы Рәшит Тәрәкый улы Исламов җыелган халык алдында

Мәчет нигезенә Гыйльмияров Хәмзә хәзрәт Коръән укый.



Манарага ай кую тантанасы. 8 июнь, 2000 ел.

ясаган чыгышында халыкны тәрбиягә, иманга чакырып торган мәчетне кыска вакытта төзеп, файдалануга тапшырырга барыбызга да бердәм эш җәелдерергә кирәк, диде...

Мәхәлләне күтәрүдә матди яктан ныклы булган оешмалар, предприятиеләр турыдан-туры катнашты. Мәсәлән, директоры Айдар Рафаэль улы Әгъзамов булган МПМК җәмгыяте сыйфатлы итеп төзи, һәр эшне зур җаваплылык белән башкара. «Шулай булырга тиеш тә, изге йорт бит бу», – дип, еш телгә ала директор төзеткән чакта. Шулай ук, Зәбир Карам улы Сәрвәртдинов җитәкләгән «Сельэнерго» акционерлар җәмгыяте эшчәннәре аңа ут үткәрә, биек манара өстендә нур сирпеп торган ай эшләтә.

Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров бирелдәге күп эшләрне башлап йөри, төзелешне тизрәк

Мавлютова Сафа Мәүләви кызы һәм Әмирҗанова Әклимә Кашафетдин кызы.

Валинурова Мәсүә Габделәүхәт кызы.

Балтач җәмигъ мәчетенең мөәзине Рауф хәзрәт Әхмәтсафа улы, мәчет әгъзасы Аскаров Әнгам Факаетдин улы, мәчетнең хуҗалык җитәкчесе Закиров Фирдус Мәсгут улы, мәчетнең мөгаллиме, шәригать белгече Камалтдинов Филүс Нәкип улы.



Мәчет ачу тантанасы.

тәмамлау хәстәрен күрә. Район хакимияте башлыгы Айрат Мәгъзүмов эш барышы белән әледән-әле кызыксынып, ярдәм итеп тора. Шулай, гомум тырышлык белән авылда мәчет күтәрелә, ямь арта, күңелләрдә иман нуры ныграк балкый...

Мөселманнарның изге йорты – мәчет ачу тантанасы 2001 елның 8 июнь көнендә үткәрелде.

Мәчет ачу тантанасы.

Районда җәмигъ мәчет ачу тантанасын Екатеринбург шәһәреннән бу күркәм мәҗлескә килгән имам-хатыйб Коръәннән аятьләр уку белән башлап җибәрде.

Мөхтәрәм кунаклар бик күп иде. Алар белән Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хажи Шәйхәйдаров таныштырды. Кунаклар арасында Русия һәм Европадагы БДБ илләре мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Баш мөфти Тәлгать Таҗетдин, Мисырдан килгән кунак Әхмәт Камил, БР буенча Баш федераль инспектор Рөстәм Хәмитов, «Башсельхозтехника» дәүләт авыл хуҗалыгы унитар предприятиесе генераль директоры,

Баш мөфти Тәлгать Таҗетдин ОАО «Сельэнерго» җитәкчесе Сәрвәртдинов Зәбир Карам улына бүләкләрен тапшыра.

Балтач мәчетен төзү оешмасы җитәкчесе Әхмәдуллин Мөккамил Җиһаннур улы.

БР Дәүләт Җыелышының Вәкилләр палатасы депутаты Дамир Фәйрушин, БР Дәүләт Җыелышының Законнар чыгару палатасы депутаты Р. М. Латыйпов, БР Фәннәр академиясенең әгъза-корреспонденты, БР һәм РФнең атказанган фән эшлеклесе, профессор, якташыбыз Фәнгать Хәмәт улы Хажиев, БРның атказанган сәнгать эшлеклесе Фәрдүнә Касыйм кызы Касыймова, Башкортстан телевидениесендә «Җомга» тапшыруын алып баручы Яркәй хажи, Уфа мөселманнарының «Нур» җәмгыяте рәисе һәм имамы Ирек хәзрәт, Норильск шәһәре баш имамы Сәлмән хәзрәт, Дүртөйле, Тәтешле, Аскын, Караидел районнары, Татарстан Республикасы шәһәреннән, Бөре, Нефтекамадан дини оешмалар вәкилләре катнашты.

Тантанада район хакимияте башлыгы, БР Дәүләт Җыелышының Вәкилләр палатасы депутаты Айрат Муллый улы Мәгъзүмов, Баш мөфти Тәлгать Таҗетдин һәм килгән кунаклар чыгыш ясады. Рәфис хажи ясаган чыгышында мәчет төзүдә зур өлешләрен керткән оешма җитәкчеләренә, аеруча «Балтач» механикалаштырылган күчмә колоннасы җитәкчеләре Мөккамил Җиһаннур улы Әхмәдуллинга, Айдар Рафаэль улы Әгъзамовка һәм эшчеләренә, авыллары халкына, гомумән, матди ярдәм күрсәткәннәрнең барысына да рәхмәт белдереп, изге теләкләрен юллады.

Иске Балтач мәдрәсәсенең мөдәррисе Филүс хәзрәт манарадан моңлы азан ишеттерде. Ахырда мәчет эчендә өйлә намазы укылды.

Балтач мәчетен төзү оешмасы җитәкчесе Әгъзамов Айдар Рафаэль улы.

Балтач муниципаль район хакимияте башлыгы Галләмов Р. Ә. Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәткә рәхмәт хаты тапшыра.

Балтач мәчете җәмәгате.

БОГДАН АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

Имам-хатыйб Нуриев Мөхәммәтнур Нурмөхәммәт улы.

Богдан авылына 1742 елда нигез салына. Архив материалларында Богдан авылында биш мәчет күренә. Билгеле, халык телендә дүрт мәчет булуы исбатлана. Мәхәллә теркәүгә кертелгән, ә мәчет төзелеп өлгермәгән булырга да бик мөмкин. Теркәлгән бу мәчетләрдә муллалар, мөәзиннәр, имам-хатыйб һәм мөдәррис-укытучылар Мөхәммәтмортаза Мөхәммәтҗанов, Әбделкәрим Әсләмов, Зиннуз Хәйрилбәширов, Җамалетдин Әглетдинов, Сәгъдивәнәл Вәлитов, Ибәтулла Рәхмәтуллин, Әбделкарам Мөхәммәтсадыйков, Кәлимулла Насыйбуллин, Җиһангир Солтангәрәев, Садертдин Габитов, Габдрәхим Җәлетдинов кебек дин эшлеклеләре була.

Кала як дип йөртелгән мәчеттә Янгир исемле кеше мулла, ә мөәзине Хәким булалар, Урталык мәчетендә дә мулла Янгир, мөәзине Вәсфи, Кантун тау башта мулла Габдрахман, мөәзине Кашаф һәм авыл очындагы мәчеттә муллалар Садертдин, Хәмәтнур һәм мөәзине Шәмсетдин исемле кешеләр була.

Тарихи чыганакларга караганда, мәчетнең берсе ике манаралы була. Җиде метр биеклектәге ике манараны авылының төзү остасы Кәлимулла Рәхмәтуллин Тушкыр һәм Богдан авылы мәчетләренә төзи.

Озак еллар имам вазыйфасын башкарган Сагитов Минегали Сагитҗан улы кызы Фәхимә белән. 1938 ел.

Богдан авылында беренче мәчет 1750 елда ачыла. Мулласы Ташбулат исемле кеше була. Икенчесе – 1850 елда, ә өченчесе, мәгълүматлар буенча, 1870 елларда төзелә. 1898 елда янгын чыгып, егерме хуҗалыкның йорт-каралтысы һәм беренче мәхәлләнең мәчете янып бетә.

1908 елда дүртенче мәчет төзелеп, беренче мулласы Садертдин, икенчесе Шаһҗиян була.

Богдан авылында да мәчет урынына нигез салынды (нигез өчен Хәлил Гыйләҗев бетон блоклар кайтартты). Моның өчен авылның иң күркәм, ямьле урыны сайланды. Бу изге эш авыл мулласы Рафаил Габдуллин тәкъдиме белән башланды. Беренчеләрдән булып шушы тәкъдимгә мәчет төзетү өчен сәдака итеп Гатика Каюмова, Фәйзия Хөсәенова, Әгъзам Латыйпов һәм башкалар пенсия акчаларын бүлделәр. Шулай ук авылда туып-үскән, әлеге вакытта читтә яшәгән богданлылар да изге башлангычка ихлас кушылып, матди ярдәм күрсәттеләр.

Чикләнгән җаваплылыктагы «Россия» җәмгыяте директоры Фидәрис Әгзәм улы Гарипов күрсәткән ярдәм белән авыл халкы зур өмә ясап, мәчет бинасын бурады. Барлык материаллар тупланды, мәчетнең манарасы да төгәлләнү алдында тора.

Имам-хатыйб Габдуллин Рафаил Мәҗит улы.

ЯҢА ЯМУРЗА АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

Яңа Ямурза авылы мәчетен төзүчеләр.

Балтач район хакимиятенең мәдәният бүлеге мөдире Сәрвәртдинов Гали Карам улы мәчет ачылу тантанасы белән тәбрик итә.

Мәчет ачу тантанасы белән Роза Фәрит кызы тәбрик итә.

2007 елның көзендә Яңа Ямурза авылында мәчет ачылды. Шушы авылда гомер итеп, фани дөньяны калдырган Фәрит Таһировның йорты мәчет сыйфатында хезмәт итү эшен башлады бу көнне. Мәрхүмнең кызы Роза, тормыш иптәше, туганнары, апалары белән киңәшләшеп, шундый изге карарга килгән.

Мәчетне ачу тантанасында Роза Фәрит кызы: «Авылдашларымның рухи камиллеккә омтылуы, динне үз итүе тик яхшылык билгесе ул», – диде.

Сынаулы тормыш юлын үткән, әтисенең үз куллары белән төзегән йортында азан тавышы яңгыравы, догалар укылуы бик матур һәм фәһемле дәвам буларак билгеләнде. Яңа Ямурза мәчетендә эшләү өчен җаваплы вазыйфага Кави Әхмәтсафа улы һәм Фәнис Мөхәммәтдин улы билгеләнделәр. Бирегә дин асылын өйрәнеп, махсус белемгә ия булган кеше килгәнче, җитди эшне тормыш тәҗрибәсенә ия булганнар башкаруы урынлы булыр, дигән фикерне һәр кеше дә хуплады.

Мәчетне ачу тантанасында Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров җыелучыларны бу якты рухи бәйрәм белән тәбрикләде. Шулай ук бирегә ерак араларны якынайтып, тантанада катнашырга зур теләк белән килгән Уфа шәһәренең Совет районы, Күгәрчен, Борай, Аскын районнары,

Свердловск өлкәсенең Сысерть районы мөхтәсибәтләренең имам-мөхтәсибләре Рәҗәп, Радиф, Илдар, Мөхәммәт, Хәкимҗан хәзрәтләр бу тантананың әһәмияте хакында сүз алып барды. Район хакимияте башлыгы Рәфил Галләмов, Югары Янактай авыл Советы авыл биләмәсе хакимияте башлыгы Рәфисә Әхәтова, чикләнгән җаваплылыктагы «Рассвет» җәмгыяте директоры Рафаэль Кашаповлар зур теләк белән катнашты һәм чыгышларында Аллаһы Тәгалә исемен данлаучы йортка илтүче сукмак өзелмәвен, олысы да, яше дә бирегә килеп торсын, дигән теләк белдерделәр.

Гомумән, динне ихтирам иткәннәр, биредә күңел тынычлыгы табар, тырышып эшләргә илһам алыр, иртәгәсе көннең изгелегенә, яктылыгына ышаныр дигән өметтә калдык.

Мәчет ачу тантанасында.

ТЕКӘН АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Озак еллар имам вазыйфасын башкарган Хәлиуллин Хәйрулла Хәлиулла улы (1885–1963).

Текән авылындагы борынгы мәчетнең беренче имамы Сәйтәк авылыннан килгән Таһир Шакир улы була. Ул 1931 елда сөргенгә озатыла һәм шунда вафат була, дигән хәбәр килә. Аннары имамнар: Хәйрулла Хәлиулла улы Хәлиуллин, Әхмәтфаиз Хасип улы Саитов һәм Фәтхелбаян Мөхетдин улы Солтангәрәевлар була. Динне кысулар башлангач, мәчет бинасын мәктәп интернаты итеп кулланалар. Әмма мәктәптә балалар саны кимүе сәбәпле, интернат файдаланылмый. Һәм аны беркадәр тузгач, сүтеп, ятимнәргә утын итеп бирәләр. Шул ук урынга яңа интернат бинасы төзелә, анысы да юньле-рәтле файдаланылмый. Район авылларында Аллаһы йортлары төзелә башлагач, Текән авылы халкы да үзләрендә мәчет булдыру уе белән Шәвъяды авыл Советы рәисе Валдиян Бадамшин белән киңәшләшәләр. Бу 1998–1999 еллар була. Һәм интернатны сүтеп алып, мәчет итеп салырга дигән фикергә киләләр. Чөнки дин кануннарын үтәү өчен мәчет булдыру уе авылда күпләрне борчый иде. Оештыручысы Назыйф Фәтхелбаян улы Солтангәрәев була. Бу изге эштә Рәкыйп, Рәсүл, Флүр Сәләховлар, Фәнис Солтангәрәев, Рәсих Хәлиуллин, Илдар Сафиуллиннар һәм башкалар зур тырышлык сала. Күмәк көч белән кыска вакыт эчендә күп эшләр башкарылды. 2000 елда инде картлар мәчеткә җомга намазына йөри башладылар. Авыл халкының теләкләре тормышка ашты.

Иганәчеләр Дамир Гыйлемшин, Ринат Дәүләтовлар ярдәме зур булды. Радик Саяпов мәчетнең манарасын эшләде. 2003 елның 5 декабре, җомга көнне, мәчетне ачу тантанасы үтте. Тантанада район хакимияте башлыгы Айрат Мәгъзүмов, Шәвъяды авыл Советы башлыгы Ә. Әлетдинов һәм дин әһелләре: Бәйсез Дәүләтләр Берлегенең Европа

Озак еллар имам вазыйфасын башкарган Саитов Әхмәтфаиз Хасип улы (1897–1987).

өлеше, Себер һәм Балтыйк буе илләре Үзәк Диния нәзарәте имам-хатыйбы Ирек Наил улы Мостаев, Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров, Түбән Сикияз авыл мәчете имам-хатыйбы Вәсил Газизов, Түбән Кансөяр авыл мәчете имам-хатыйбы Барый Латыйповлар катнашты.

Аларның һәрберсе котлап ясаган чыгышларында истәлекле бүләкләр тапшырдылар һәм авыл халкының киләчәктә мәчеткә йөреп, дин кануннарын үтәрләр дигән ышаныч белдерделәр.

Озак еллар имам вазыйфасын башкарган Солтангәрәев Фәтхелбаян Мөхетдин улы (1914–2008).

Имам вазыйфасын башкаручы Сабиров Нух Дәүләтхан улы.

Үзәк Диния нәзарәте вәкиле Мустаев Ирек Наил улы мәчет ачу тантанасы белән тәбрик итә.

Текән мәчетен ачуда катнашучылар.

КӨНДӘШЛЕ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ





Имам-хатыйб Фаттахов Глимҗан оныклары белән.

Узган гасырның башында Көндәшле авылында мәктәп булмаган. 1920нче елларга кадәр дин әһелләренең үз өйләрендә яисә мәчетләрдә шәкертләр укытулары билгеле. Әхсән һәм Нурлыгаян муллалар, мөәзин Әхмәтшәриф Мостафиннар шушы эш белән шөгыльләнгәннәр. Ике мең ярымнан артык кешеле, 500 йортлы авылда өч мәчет булган.

Караидел районына кергән күрше авыл – Тайкашта зур мәдрәсә эшли. Авылдан ике кеше – Нәртдин Фәхретдинов һәм Мөхәммәтнур Дәүләтшиннар шушы мәдрәсәне уңышлы тәмамлыйлар.



Имам-хатыйб Зиннуров Валинур, имам вазыйфасын башкарган Сафетдинов Нәгыйм, Хәмәтнуров Мазһар Мөхәммәтнур улы, Вильданов Фагъдан Абдулла улы.

Мөхәммәтнур солдат хезмәтендә чагында Житомирда рус мәктәбендә белем ала. 1903 елда хезмәтен бетереп кайтканда, Ырынбурга кереп, ике указ алып кайта: муллалыкка һәм авылга икенче мәчет салырга дигән рөхсәт указы.

Авыл халкы озын арба әзерли. Көндәшле урманында бу дәвердә мәчеткә яраклы агач булмый. Мөхәммәтнур указны тотып Аскын районына юл ала. Указ нигезендә, Мунчадар

Имам вазыйфасын башкарган Сәхипов Әбелгайнан тормыш иптәше Нәзифә Галиәскәр кызы белән.

Имам-хатыйб Хәмәтнуров Илшат Мазһар улы.

дигән авыл урманыннан агач бирәләр. Авылда иң бае Мостафа дигән кеше була. Аның 4 келәт игене, берничә дистә аты, 40–50 дисәтинә җире була. Мәчет салдырырга Мостафа карт бер келәт игенен бирә, ун аты булган Әфтах исемле карт Мөхәмматнурга бер атын бирә. Бер ай эчендә Мунчадардан озын арбаларга төяп мәчет агачын Көндәшлегә ташып бетерәләр. Мәчет ике елда файдалануга тапшырыла. Бу мәчеттә Мөхәмматнур хәзрәт 1932 елга кадәр имам-хатыйб вазыйфасын башкара, Шәйнур Юнысов мөәзин була. 1816, 1833, 1850, 1859 еллардагы ревизия мәгълүматларына караганда, авылда шушы ике гасыр эчендә уннан артык указлы муллалар: Әбделгани Гәбделгалимов, Әхсән Әсләмов, Нуриәхмәт Хәсәнов, Хисаметдин Гайнуллин, Вәлинур Дәүләтшин, Глимҗан Фәттахов, Фәйзелкарам Мәхмүтов һәм унбишләп указлы мөәзин: Әбделгалим Гайнуллин, Мостафа Мофазалов, Әхмәтшәриф Мостафин, Шәйнур Юнысов, Локман Гыймазетдинов, Сафетдин Сәхәбетдинов һәм Габбас

Намазга йөрүчеләр.

Зәйнетдиновлар булган. Совет чорында имам вазыйфасын алып баручылар: Галинур Зиннуров, Глимҗан Динисламов, Туктамыш Рәхимов, Корбан Нәртдинов, Мәгасум Сәетгалиев, Нәгыйм Сафетдинов, Гайнан Сәхипов һәм Фәгъдан Вилдановлар.

1932 елда муллалык указыннан баш тартмаганы өчен Мөхәммәтнур төрмәгә утыртыла һәм шунда гомере өзелә. Мөхәммәтнур хәзрәт салдырган мәчетне сүтеп, мәктәпкә остаханә итеп салдылар, өске катында ике класс укыды. Хәзрәтнең 4 баласы кала. Иң кечесе Мазһар Хәмәтнуров 1925 елда туган. Көндәшле авылы ветераннар советы рәисе, ике Кызыл Йолдыз, Ватан сугышы орденнары, «Берлинны алган өчен» һәм башка бик күп медальләр кавалеры, бүген дә сафта.

1992 елда, динебез аякка баскач, Мазһар Мөхәммәтнур улының бер генә теләге – әтисенең мәчете урынына яңа мәчет салдыру нияте була. Шуны хәстәрләп йөри башлый ул. Авылда 1998 елда мәчет төзү уе белән 9 кешедән мәхәллә төзелә. Мәчет төзергә рөхсәт алу өчен район хакимиятенә хат языла. Рөхсәт алынгач, делянкалар юллап алына, өмәләр башлана. Мәчет төзүдә Көндәшле авыл халкы актив катнаша. Әлбәттә, бу изге эштән җитәкчеләр дә читтә кала алмый. Мәчетнең нигезеннән башлап тәмамланганчы оста эшләрен Мазһарның олы улы Нәфис Хәмәтнуров алып бара. Мәчетнең манарасын да, аен да Әдип Лотфуллин белән башын күтәреп япкан дәвердә үзе куя. Бу изге эштә катнашучы осталар: Әдип Лотфуллин, Тәбрик Гыйзетдинов, Рәфиз Басимов, Рәис Такаев, Кадим Кашапов, Рифат Нуртдинов, Габдинур Җиһангиров, Рәшит Хәмзиннар һәм башкаларның тырыш хезмәт салуы нәтиҗәсендә мәчет төзелеп бетә.

Мәчет ачу тантанасы 2006 елда үтә. Мәчетне төзүдә аның нигезен салудан һәм бурасы өчен агач кисүдән башлап, манарасы башындагы аен куюга кадәр барлык эшне сугыш һәм хезмәт ветераны Мазһар Мөхәммәтнур улы Хәмәтнуров оештыра һәм җитәкчелек итә.

ЧУРТАНЛЫКҮЛ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

Имам-хатыйб Риянов Ризван Җамалия абыстай белән.

Авылның йөзек кашы чишмә булса, рухи йорты – ул мәчет. Татар авылларында гыйбадәт йорты аеруча мөһим рольне алып тора. Моннан башка яшәүне күз алдына да китерү мөмкин түгел.

Чуртанлыкүл авылында соңгы мәчет 1844 елда төзелгән. Ул агач бурадан булган. Мәчетнең имамы Чокалы авылыннан килгән

Риянов Ризван булган. Халык аны бик укымышлы, гыйлемле хәзрәт итеп искә ала. Аның җәмәгате Җамалия абыстай да бик дини, тәкъва була, бик күп кешеләр аңа килеп, дәва таба торган булганнар.

1934 елның 20 октябрендә үткән гомуми җыелышта мәчетне культура йорты итеп алырга тәкъдим ителә. Анда яңадан клуб салырга көч җитмәве искә алына, гает намазлары уку өчен ярты гына чакрым җирдә Югары Карыш авылы мәчетенә йөрергә дигән карарга киләләр. Мәчет бинасының өске ягында җәмгыять клубы, астына мәктәп мастерское һәм ашханәсе урнаштырырга планлаштыралар. Бу җыелыш карары бер тавыштан кабул ителә. 1935 елның 17 январендә БҮБК Президиумы постановлениесе чыга һәм авылдагы мәчет культура йортына әйләндерелә.

Илекәй авылы мәчете



Күптән инде 80 яшен тутырган Илекәй авылы аксакалы Бәләгытдин бабай (мәрхүм инде, урыны җәннәттә булсын) үз авылларында, үз өйләренә ерак түгел генә өр-яңа мәчет калкып чыкканчыга кадәр, һәр җомга саен матур киенеп, Иске Яхшый авылындагы бердәнбер сакланып калган Аллаһы йорты – мәчеткә җәяүләп намазга йөрде. Мин аны еш очрата идем. Һәм очратканда исәнләшәм дә: «Бәләгытдин бабай, аякларың сызлап интектергәнен беләм, синең яшьтә авылдан авылга җәяү йөрүе бик авырдыр бит», – дим. Ә ул исә ихлас елмаеп: «Аллаһы Тәгалә ярдәме белән йөрим, Хозыр Ильяс юлдашым, әле менә аның белән юл буе «сөйләшеп» киләм», – дип җаваплый…

Бабай инде Иске Яхшый авылы мәчетенә йөри алмый башлауга үз йорты янында гына өр-яңа мәчет бинасы калкып чыкты…

Ярты елдан артыграк кына вакыт эчендә аны кем төзетте соң?

Бәләгытдин бабайның олы улы Әлфир Шәйхетдинов башка авыл балалары кебек үк елгада су коенып, көтү көтүләп үсте. «Башсоцинвест» коммерция банкының идарә рәисе (хәзер лаеклы ялда). Бәләгытдин бабайның Согуд Гарәбстанының иң борынгы шәһәре Мәккәдәге мөселманнарның изге йорты Кәгъбәгә гыйбадәт кылырга бару теләге дә бик зур иде. Улы аның шушы теләген дә тормышка ашырды. Аннан алып кайткан изге судан бик күпләрне авыз иттерде, Аллаһының рәхмәте яусын аңа…

Әлфир Бәләгытдин улының динебезне ихтирам итүенең икенче мисалы булып үз хисабына туган авылында манаралы яңа мәчет төзетү булды. Әнә шулай эшне бик кызу тотып, Радиф Кашапов җитәкчелегендә бригада әгъзалары бинаны Корбан гаете көннәрендә файдалануга тапшырдылар.

Мәчетне ачу тантанасында кунаклар да күп булды. Пакистанның Карачи шәһәреннән Әбделхалик һәм Әбдерахман хәзрәтләр, Төркиянең Спарта шәһәре кунагы Мостафа Кая хәзрәт, БДБнең Европа өлеше, Балтыйк буе илләре һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Тәлгать Таҗетдин һәм Рәвил хәзрәт, район хакимияте башлыгы Рәшит Исламов һәм башкалар катнашты.

«Мин үземнең ата-анамның иске йортын яңартудан башламадым, ә мәчет – Аллаһы йорты төзү барысыннан да мөһим булуын уйлап төзеттем, – диде Әлфир Бәләгытдин улы чыгышында. – Чөнки мөселман илләрендә нинди дә булса авыл төзергә кирәккәндә – иң тәүдә мәчет салып куялар икән…»

Рәфис хәзрәт Коръәннән аятьләр укырга сүзне Пакистаннан килгән кунакка бирде. Аның моңлы тавышы авыл өстенә агылды. Аннары Баш мөфти Тәлгать Таҗетдин тирән эчтәлекле вәгазь сөйләде…

Мәчетне төзетүдә катнашкан районның барлык оешмаларына, аерым кешеләргә рәхмәт белдерелде.

«МӨХӘММӘТЗЫЯ» МӘЧЕТЕ



Мәчет төзүчеләр: Галләмов Мөдәррис, Низамов Салават, Низаметдинов Назыйф, Нигъмәтуллин Фагит.

Нөркә авылындагы «Мөхәммәтзыя» мәчете 2006 елның июнь аенда районда «Салават җыены» милли-фольклор бәйрәме алдыннан бер көн элек ачылды.

Авылда электән мәчет булган. Тик заманалар агымы үзгәрү белән ахырга таба ул мәктәп итеп файдаланыла башлаган, балаларга белем бирү бинасына әверелдерелгән.

Авылда туып-үскән, читтә яшәүче Зәниф Мөхәммәтзыя улы Низаметдиновның үз авылында Аллаһ йорты төзетү дигән изге уе була. Шушы хыялын тормышка ашыру исәбе белән 2005 елда авылның нәкъ уртасында урнашкан элекке авыл Советы бинасын сатып ала...

Низаметдинов Зәниф Мөхәммәтзыя улы.

Балтач муниципаль район хакимияте башлыгы Галләмов Р.Ә. мәчет ачу тантанасы белән тәбрик итә.

Ир-егет гомерендә гаилә корырга, ир бала үстерергә һәм агач утыртырга тиеш, диелә халыкта. Зәниф шуларның барысын да үтәгән. Әмма шушы әтисе рухына багышлап, авылларында мәчет ачу хыялы иң зурларының берсе була. Димәк, анысын да тормышка ашырган ул.

Аны ачу тантанасында Башкортстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәммәт хәзрәт Нигъмәтулла, муниципаль район хакимияте башлыгы Рәфил Галләмов, Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров, авыл Советлары хакимиятләре башлыклары, район авыллары һәм күрше районнардан да дин әһелләре катнашты.

Авыл аксакаллары: «Иман йорты начар эшләрдән тыелып, бер-береңә изгелекле, миһербанлы булырга, хәрәм белән хәләлне аера белергә өйрәтер, кыска гына гомеребезне иман белән, матур үткәрик», – диделәр, чыгыш ясап.

ИСКЕ ТУШКЫР АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

Кәлимулла уллары Фархулла һәм Дәүләтгәрәй Рәхмәтуллиннар.

Иске Тушкыр – гыйбадәтханәләр тарихында ике манаралы мәчете булган авыл буларак аерылып тора.

Авылга 300 ел элегрәк нигез салына. Һәм ислам динен тоткан ата-бабаларыбыз гыйбадәт йортлары – мәчетләр төзү хәстәрен күрә башлыйлар. Авылда өч мәчет (өч мәхәллә) була. Беренче мәчет 300 ел чамасы элек салынган.

Күп манаралы мәчетләрне мөселман шәһәрләрендә генә күрергә мөмкин. Авыл мәчетләре, гадәттәгечә, бер манаралы. Ә менә элекке Уфа губернасындагы авылларда бердән артык манаралы мәчетләр булганмы? Булган. Архитектурасы буенча башкорт халкының төзелеш сәнгатенең иң үрнәклесе дип әйтергә тулы хокуклы мондый мәчет районның Иске Тушкыр һәм Богдан авылларында да булган.

Ике манаралы мәчет авылның көньяк-көнчыгыш ягында, бар яклап та күренеп торган иң калку урынында (хәзерге Фрунзе урамында) урнашкан. Борынгы картлар сөйләве буенча, бу мәчет 1891 елга кадәр манарасыз була. Тик 1891 елда Тушкыр авылының киң танылган мастер-төзүчесе, төзелеш сәнгате остасы Кәлимулла Рәхмәтуллин житәкчелегендә мәчетнең ике ягына 7 метр биеклектәге ике манара күтәреп куялар. Манаралар арасында гөмбәзе дә булган, тик анысы сугыш башланган елны

Вахитов Хәблислам.

Шәйхуллин Тахирҗан.

Имаев Мөхтәрәм.

Вәлиәхмәтов Фоат.

сүтелә. Мәчет тыштан 4,6 метр биеклектә була, эче ислам дине таләпләренә ярашлы, зурлыгы буенча заллар икегә бүленә. Зур зал – фарыз бүлмәсе, кече зал – сөннәт бүлмәсе. Кышын мәчетне

жылыту өчен ике мич: берсе түгәрәк (халык телендә голландия мичe), икенчесе – дүрт почмаклы була. Шул ук вакытта мәчеткә ремонт үткәрәләр. Фаразлар буенча Башкортстанда ике манаралы мәчет проектын иң беренче булып Кәлимулла Рәхмәтуллин уйлап чыгара. Аның кулы һәм проекты буенча Яңавыл районының Гөтбер, Ташлы Елга авылларында, Аскын районында Кыйгазы авылында һәм Татарстанның чиктәш районнарының Әҗи һәм Иске Теләк авылында мәчетләр төзелә. Ике улы Фәрхулла һәм Дәүләтгәрәй дә оста төзүче була. Гомумән, аларның осталыгы буыннан-буынга килә.

Кәлимуллиннар көче белән Иске Тушкырда икенче мәчет төзелә. Ул авылның нәкъ уртасында, Үзәк урамда урнашкан була. Өченче мәчет халык телендә «Типтәр мәчете» дип йөртелгән.

XVIII гасырда Иске Тушкыр авылына Идел буеннан, чукындырудан качып Габҗәлил, Сабит, Туктагул исемле кешеләр килеп урнаша. Алар бик эшчән, алдынгы карашлы иген игү осталары булалар. Соңрак тагын берничә гаилә күченеп килә. Аларга җир бүлеп бирәләр. Авыл халкы белән бик тату, бер гаиләдәй дус яшиләр. Алар авылның көньяк өлешенә төпләнәләр. Шушы вакытларда Габҗәлил мәчет төзетә. Бу мәчет авыл эчендәге зират янында (хәзерге Базар урамы) булган.

Мәчетләрнең соңгы язмышларына килгәндә, өченче мәчет 1936 елларда сүтелә һәм материаллары мәктәп төзелешендә кулланыла. Үзәк урамдагы икенче мәчет 1953 елда сүтелеп, шулай ук мәктәп итеп файдаланыла. Күчереп салганчы, 1940 елдан башлап, башлангыч мәктәп була. 2008 елда аның бинасын сүттеләр. Ике манаралы мәчет исә 1960 еллар башында сүтелеп, күчереп, мәктәпнең физкультура залы һәм хезмәт дәресе классы итеп файдаланылды. 2009 елда, янгын чыгу куркынычы сәбәпле, ул бина да сүтелде. (Материаллар Тушкыр урта мәктәбенең «Крайны өйрәнү музееннан» һәм «Архитектурные памятники Башкирии» китабыннан (авторы Б. Кәлимуллин) алынды).

Фоат Вәлиәхмәтов истәлекләреннән: «Бөек Ватан сугышы барган елларда (авылда олылар сөйләве буенча монысы икенче мәчет булган) безне мәчеттә тукландырып йөрттеләр. Мөәзине Усман исемле бабай иде. Мәчет ике катлы, аста подвалы да биек кенә иде. Сугыштан соң да әле без 5–6 ел чамасы шунда укыдык…»

«Урал» колхозы 90нчы елларда колхоз үзәге Тушкыр авылында шул ук участок больницасының уң яктагы урамыннан кергән урында гостиница төзетә. Һәм ул берничә ел файдаланылмый утыра. Авыл картлары колхоз идарәсеннән аны мәчет итеп файдалануга рөхсәт сорыйлар…

1990–1993 елларда Тушкыр авылында мәхәллә оештырыла. Аны оештыруда Хәблислам Әдегелислам улы Вахитов һәм Мөхтәрәм Имай улы Имаевлар башлап йөриләр.

Мәчеттә өмә. 2010 ел.

1993 елның февраль аенда мәчеткә олысы да, яше дә йөри башлыйлар. Әмма мәчетнең манарасы булмау мөэминнәрнең беркадәр кәефен кыя. Бу хакта еш кына сүз алып барыла, тик нишләптер, җөрьәт итеп, эш башлаучы гына булмый. Шулай итеп 5–6 ел чамасы вакыт үтә. Һәм бу эшкә: шул ук Фоат абый белән бар эшне дә белгән, уңган һәм булдыклы авылның электригы Фәтих Шакиров эретеп ябыштыру эшләрен башкара.

МИШӘР АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

Галиева Флидә Факаетдин кызы.

Гильмуллина Гүзәл Хаккый кызы.

Заманында Мишәр авылында мәчет һәркем өчен изге йорт булган. Әмма мәчетләрне бетереп, манараларын кисеп, башка максатка файдалану башлангач, аны да мәктәп итеп файдалануга бирәләр. Ләкин мәчетләрне бетерү рухны сындыра, иманны юк итә, гореф-гадәтне какшата алмаган.

Әнгам абый Мостафин истәлекләреннән: «Мишәр – районда дин әһелләрен күпләп чыгаручы авыл буларак билгеле. Гомере буена Насретдин Гайнетдин улы Баутдинов мәчеттә мөәзин булган. Аның уллары Сөләйман, Гали указлы муллалар була. Дин әһелләре Абзалтдин Низаметдинов, Малик Кашапов һәм башкалар иң авыр чорларда да динне саклап, килер буыннарга тапшыручылар исәбендә».

Ислам дине тергезелә башлагач, Мишәр авылында да мәчетне аякка бастыру турында сүз кузгатыла. Бу изге уй шушы авыл кызы, ветеран-укытучы Флидә Факаетдин кызы Галиева белән аның кызы Гүзәл Хаккый кызында уяна.

Флидә Факаетдин кызы истәлекләреннән: «Динне кыскан чакта авылда дини йолалар башкару тукталмады. Мәчетнең манарасын кискәнче, күрше Яңа Балтач авылыннан указлы мулла Хәсән бабай һәр җомга саен мәчеттә җомга намазына килүен, ул вакытта кечкенә булсам да, хәтерлим. Һәм авыл кешеләре аны (авылдан Мөхлис бабай белән бергәләп) дини йолалар башкарырга чакыралар иде. Без дә нәселебез белән дини кешеләр булганбыз. Заманында әнием Фәсәхәт, зур әтием Мөхәммәтҗан, аның уллары Муллануp, Фазыл һәм Хәмәтдин Субышев бабай, Нәгыймә, Хәтирә, Сафия, Сәмига абыстайлар үз гомерләре буе дини йолалар башкарган кешеләр. Әйткәндәй, бертуган апам Флүрә Мишәр авылында укымышлы абыстай, Иске Балтачта яшәүче абыем Әнгамнең дә дини йолалар буенча үткән мәҗлесләрдә урыны түрдә».

Мәчеткә ай кую тантанасы. 2010 ел.

Билгеле, каршылыклар да була, тик изге эш намуслы кешеләр арасында тиз яклау таба. Туганнары, дуслары, авыл халкы бердәм тотынып, мәчеткә реконструкция үткәрү эше башкарылды. Гомумән, күп кешенең уңган кулы тиде бу изге эшкә, район үзәгеннән дә, күрше авыллардан да килеп булыштылар, хәтта мәктәп укучыларының да ярдәме тиде. Шулай итеп, авылның һәр ягыннан күркәм булып чагылып торган манаралы мәчет тергезелде: бинасы да, тирә-ягы да бизәлгән, тышланган, буялган, ныгытылган. 2009 елдагы Корбан гаете бәйрәме яңа мәчеттә үткәрелде.

Авылда мәһабәт изге йорт калкып чыгуына халык чиксез шатлана. Мулла Рәшит Хәмит улы Мәхмүтов һәм Яңа Балтачтан Малик Әгъләм улы динне тәрбия чарасы итү өчен бар тырышлыкларын салалар.

– Изге йортка «Әнием» мәчете дигән исем биреләчәк. Мәчет бусагасына атлар алдыннан һәркем шушы изгеләрдән булган «Әнием» сүзен укып, әнисен исенә төшереп, аларның кадерен белсен дигән максаттан чыгып сайланды бу исем, – ди Гүзәл Хаккый кызы.



Мишәр авылы мәчете дә киләчәктә үзенең изге вазыйфасын үтәп, халыкны изге уй-нияттә берләштерүгә, күңелләребезне сихәтләндерүгә өлешен кертәчәк, иншалла.

СӘЙТӘК АВЫЛЫ МӘЧЕТЛӘРЕ



Озак еллар имам вазыйфасын башкарган ике сугыш ветераны: Вәлиәхмәтов Вәлиәхмәт, имам-хатыйб Кашфулла хәзрәт, имам-хатыйб Фоат хәзрәт.

Сәйтәк авылы Балтач районында иң зур авылларның берсе. Авыл гомер-гомергә үзенең динлелеге, иманлы кешеләрнең күп булуы белән аерылып торган. Электән үк бу авылда өч мәхәллә, ике мәдрәсә булуы билгеле. Бу мәдрәсәләрдә танылган имамнарыбыз, хәзрәтләребез дин сабакларын өйрәткән. Кыскасы, авыл халкы үз иманын гомергә саклап килгән.

Тарихка күз салсак, үткән гасырларда Сәйтәк авылы өч мәхәлләгә бүленгән. Авыл сәүдәгәрләре, күп бай кешеләре, тимерлеге, буяу цехы, өч мәчетле, икесе каршында мәдрәсәсе булган авыл буларак телгә алына. Өч мәчетнең дә үз муллалары, мөәзиннәре халыкка хезмәт иткән. Һәр өчесе Александр II патшалык иткән заманнарда сафка баскан дигән фараз бар.

Иң олы дини кешеләрдән Шакир хәзрәт исеме очрый. Ул хәзерге Тучыбай авылына чыккан урамда яшәгән. Соңрак бу йорт яңа төзелгән колхоз мәнфәгатенә кулланыла, бераз вакыттан соң аптекага үзгәртелеп салына. Шакир хәзрәтнең әтисе Әухәди турында да олылардан бераз мәгълүмат ишетергә мөмкин. Заманына күрә бик тә укымышлы кеше булган, шуңа күрәдер дә улы Шакирга белем алырга мөмкинчелекләр тудырырга тырыша. Егет Ырымбур якларында белем алып кайта. Тормыш иптәше Канифә белән 6 балаларының барысына да белем биргәннәр.

Беренче мәхәлләнең мәчете Шакир хәзрәтнең улы Хөсәен мулла исемен йөрткән. Мәчет бинасы агачтан төзелгән, ике катлы, ике заллы, манарасы түбә уртасында. Калын аркылы дивар мәчет бинасын дүрт өлешкә бүлә. Ул диварда манарага менә торган тар баскыч ясалган. Көньяк фасадында ике кыеклы түбә белән капланган турыпочмаклы михраб чыгынтысы күренә. Мәчетнең өч ярусլы, сигез кырлы, чатыр белән очланган манарасы калын

аркылы диварда, түбә уртасында күтәрелгән. Манара буй фасадлары кучәре буенча куелган. Буй фасадларының урта өлеше өчпочмаклы фронтоны булган дүрт пилястрлы потригы белән бизәлгән. Ошбу гыйбадәтханә кырыс классицизм белән традицион стиле кушылган чагыштырмача аз очрый торган татар мәчетләре рәтенә керә. БАССР Югары Советы Президиумы башкорт очында урнашкан бу мәчетне ябып, мәхәлләнең бетерелүен раслап, мәчет бинасын мәктәпкә бирергә карар чыгара. Мәчетләрнең формасы калмасын дигән уй белән аның манарасын да кисәләр. Ничә көннәр авылдан манара кисәрдәй «батыр»ларны эзлиләр, тик авылдан бу эшне башкарырга беркем дә батырчылык итми. Халык диннән ваз кичмәгән икән. Авыл картларының сөйләвенчә, бу эштә авыл активистлары, авыл Советы башкарма комитеты башлап йөри. Атналап эшләгәч, бу эшне башкарып чыгарга кешеләр табыла. Бер уйлаганда, монда авыл түрәләренең үтә дә тырышлыгы булгандыр инде. Ни эшлисең, югарыдан килгән фәрманны үтәргә тиеш булалар, җитмәсә коммунист кешеләр. Манараның үзәк баганасын балта белән таптап кискәч, аны көнчыгыш ягына аударырга уйлыйлар, ә манара ул әмергә буйсынмыйча кыйблага ава. Манара башындагы ярымай җиргә батып керә. Менә шулай Сәйтәк авыл халкы бер мәчеттән колак кага. Күпме көч куеп төзелгән халык байлыгы дәүләт карамагына күчә. 1933 елларда мәчет бинасында мәктәп ясыйлар. Ике катлы



Мәчет ачу тантанасы. 1994 ел.

бина бик озак еллар хезмәт итә. 1980 елларда гына сүтелеп, 1988 елның көзендә урынына балалар бакчасы төзелде. Тик балалар бакчасы да озак хезмәт итә алмады, янып китте.

Икенче мәхәлләнең мәчете тау башында урнашкан. Бинасы бер катлы, ике заллы, вестибюле, түбәдәге манарасы белән, антресольле мәчетләр типына керә. Манарасы ике ярусллы, биек чатыр белән очланган. Вестибюльдән манарага тар баскыч менгән. Буралы бинаның стеналары такта белән тышланган. Фасадларның эшләнешендә халык төзү сәнгате белән классицизм архитектурасы алымнары кушылган. Бу мәчет Гилмишәрип исемен йөрткән. Шулай ук Гилмияр мулла исеме белән дә телгә алына. Мәдрәсәдә укыткан, динне һәм фәнне яхшы белгән, Казан мәдрәсәләренең берсендә укыган һәм аны уңышлы тәмамлаган Гилмияр баштарак Нөркә авылында да мулла булып торган. Заманалар чуала башлагач, Гилмияр белән Габделәхәт, ягъни бабай белән кияү, 30нчы елларда Бөре шәһәренә төрмәгә ябылуга хөкем ителә, Гилмияр мулланың хатыны балалары белән өеннән куып чыгарыла. Атлары, сыерлары уртак утарга куыла. Йорт-җирләрен хәерче генә тормыш иткән Шәмсиярлар гаиләсенә бирәләр. Тик гаилә башлыгы Шәмсияр авыл халкы ихтирам иткән мулланың дөньясын кире гаиләсенә бирә. Көн тәртибенә авылның икенче мәчетен дә сүтү турындагы карарга җыелыштагы халык каршы тора ала, тик икенче көнне идарә әгъзаларына каршы сүз әйтергә курка гади халык, чөнки аларга аңлату эше башкарылган була. Шулай итеп, икенче мәчетнең манарасы да киселә.

Өченче мәхәлләнең мәчете (типтәр очында) бер катлы, зур түгел. Биредә төп гыйбадәт залыннан тыш өстәмә зал һәм вестибюле дә бар: һәммәсе үз урынында. Вестибюль астында, аскы өй бинасында алгы бүлмә (прихожая) урнашкан. Мәчеткә бинаның көнчыгыш ягыннан, алгы бүлмә аркылы керәләр, аннан соң баскыч буена чорма белән манарага менгәннәр. Вестибюльнең көнчыгыш ягына пыяла куйдырылган веранда орынып торган. Ике кыеклы түбәле веранда ике колоннага таянып торган һәм мәчеткә керү җирен күрсәтеп торган сыман. Мәчетнең дүрт кыеклы түбәсе уртасында сигезкырлы, биек чатыр белән очланган манара күренеп торган. Манараның бүрәнәләре бүрәнәдән җыелган дүрткырлы бурага терәлә, бураның нигезендә исә түшәмнең калын матчалары ята. Бу мәчет Габделхак мулла исемендә булган. Укуга әвәс егет, үзлегеннән тырышып укый. Чыгышы белән гади авыл малае булганлыктан, аңа заман җилләре бик ачы кагылмый – сөргенгә җибәрмиләр. Бар мөлкәтен тартып алып, үз өеннән чыгарылып җибәрелә, бары тик мунчада яшәргә рөхсәт итәләр. Авыл халкы ярдәм итү йөзеннән мунча бурасы бирәбез дип, кечерек кенә өй рәтләп, мулла гаиләсенә яңа куыш коралар. Авылда сугыш вакытында бу мәчеттә имамлык иткән Дилми мулла, Гайнеглим мулла, Мулланур, Гайниәхмәт, соңрак

Кәшфулла муллалар да халыкны белемле итү өчен күп көч куйганнар.

1969 елның 14 май төнендә авылда эшләп килгән соңгы мәчет тә яна.

1990 елларга кадәр авыл картлары Миңкамал әбиләрдә тәравих, җомга намазлары укырга җыелганар. Әби-бабаларыбыз качып-посып булса да динебезне саклап, аның киләчәк буынга ирешүенә догалар кылып, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын табарга тырышканнар.

1994 елның җәендә Сәйтәк авылында яңа мәчет ачыла. Авыл аксакалы Кәшфулла абый бу изге эштә башлап йөри. Аның әйтүенчә, кыска вакыт эчендә район хакимиятенең, төрле оешмалар, авыл халкының ярдәме белән иман йортын төзүгә ирешәләр. Аны ачу тантанасына килгән БДБнең Европа өлеше, Балтыйк буе илләре вә Себер мөселманнары Диния нәзарәте рәисе мөфти хәзрәтнең мәчетләр төзү буенча ярдәмчесе Гали хәзрәт һәм Уфа мәчете рәисе Зәйнулла хәзрәт Хәсәновлар кызыл тасманы кисеп эчкә үтәләр. Иске Балтач мөхтәсибәтенең имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров мөселманнарны мәчет эчендә беренче намазны укырга чакыра.

Килгән кунаклар, Бохара шәһәреннән кунакка кайткан якташыбыз Вәсилә Фәйзелгаян кызы, район хакимияте башлыгының урынбасары Нил Нуриев, Иске Балтачтан Сәхия һәм Сафа абыстайлар чыгыш ясап, мәчетле булулары белән Сәйтәк авылы халкын ихлас котладылар һәм истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Бүгенгесе көндә бу мәчетнең имамы булып Фәтхлисламов Фоат хәзрәт хезмәт итә. Аның нәсел тамырлары да шулай ук дини кешеләргә барып тоташа.

Борынгы бабаларыбыз бик белеп әйткәннәр: үзебезнең үткәнебезне, килеп чыгышыбызны, тарихыбызны яхшылап белми, өйрәнми торып, без тыныч кына киләчәгебезгә атлап керә алмыйбыз. Тарих бит ул диңгез кебек вак-вак тамчылардан җыела, шул «тамчылар» ярдәмендә безнең үткәнебез, бүгенгебез һәм киләчәгебез формалаша.

ИСКЕ ЯХШЫЙ АВЫЛЫ МӘЧЕТЛӘРЕ



Саяфетдин хәзрәт.

Динислам хәзрәт.

Миңнебай хәзрәт.

Нәбиуллин Хәлиулла.

Районның Иске Яхшый авылы 1730 елда нигезләнә. Ә 1738 елда инде анда вакытлыча гыйбадәт урыны булдырыла. Авылның беренче имамы булып тарихи чыганакларда Атик Әймәтов телгә алынган, олылар риваятьләре буенча авылның икенче имамы булып Мирхәйдәр хәзрәт исәпләнә. Әнә шулай аның җитәкчелегендә 1737–1738 елларда беренче мәчет төзелә. Имам булып Мирхәйдәрнең олы улы эшли башлый. 1788 елны Уфа шәһәрендә «Мухаммадское Духовное собрание» ачылып эшли башлый. Шул елда Иске Яхшый авылы халкы губерния җитәкчелегенә икенче мәчет төзүгә рөхсәт сорап, дөньяви укытуга дин әһелләрен тоту чыгымнарын үз өсләренә алу турында мөрәҗәгать итә. Шулай итеп, 1800–1805 елда икенче мәчет

Мифтах хәзрәт.

Хәлимулла Мортазин.

Имамгали хәзрәт.

төзелә, яки инкыйлабка кадәр ике мәчет эшли. Соңгысы 1900–1910 еллар тирәсендә төзелгәне мәһабәт, биек манаралы була. Икенче мәчеттә дә мәдрәсәләр эшли. Ә аңарга кадәр төзелгәне (кайбер мәгълүматларда 1737 ел, ә Хөкүмәт мәгълүматларында 1797 ел йөри) исән кала. Аның манарасы да төшерелми. Һиҗри белән 310нчы елда безнең бабаларыбыз үзләренә яшәү рәвешен сайлап алып, 1917 елга кадәр шулай гомер кичерәләр. Кайсыларын сөргенгә куып котылырга исәплиләр, кайсыларын юк итәләр. Әмма халык намазларын ташламый. 1930 елдан эшләгән Иске

Яхшый авылы мәчете республиканың төньягындагы 18 район арасында эшләгән бердәнбер мәчет була. Җомга намазларына Свердловск, Пермь өлкәләреннән мөселманнар килә. Күз алдына китереп карагыз: җомга намазына өлгерер өчен бер көн алдан килеп урнашканнар, икенче көнне мәчеттә намаз укыганнар, өченче көнне кайтырга чыкканнар – нинди тәкъвалык!



Имам-хатыйб Гайфуллин Хатмулла Гайфулла улы.

1929–1930 еллардан башлап күп мәчетләр җимерелеп, муллалар сөргенгә куыла, 40 мең мулла үтерелә. Дин дәүләттән тыш итеп игълан ителә. Һәр дин дә дәүләттән башка яши ала, ә дәүләтнең диннән башка яшәве инде…икеле. Аллаһы Раббыбыз: «Динен ташлаганнардан Мин сүтәр өчен төзетермен. Кирәкмәгән эш эшләтермен», – диде. Халык ач-ялангач була. Динне бетерү күзлегеннән илдә күпме мәчет ябыла. Иске Яхшый авылының мәчете Хөкүмәт тарафыннан 1932 елда ябыла һәм бина мәктәп итеп кулланыла башлый. Гафурҗан Исламгалиев хатирәләрен яңартканда болай дип сурәтли: «Безнең бәләкәй чак иде. Әмма хәтердә калган: көндез манараны кистеләр, арканнар белән аны тартып карадылар, ул аумады. Тырышлыклары бушка китте. Кичләрен укуга халык йөри иде. Шунда килгәннәр төнлә бергәләшеп манараны тартып аударганнар».

Сугыш елларында яңа мәчет ул вакыттагы «Октябрь» күмәк хуҗалыгында атлар тоту өчен кулланыла. Бөек Ватан сугышыннан соң мәчет бинасы сүтелеп, мәктәп спортзалы итеп салына. Авылда беренче мәчет үз вазыйфасын тиешенчә башкарып килә. 1942 елда аны ябалар һәм ике ел дәвамында аның бинасын ашлык саклау өчен файдаланалар. 1945 елда яңадан мәчет ачыла һәм эшен дәвам итә. Бу еллар дәвамында авылда имам булган Абзалтдин, Миңнесафый Әкмәлетдин улы Әхкәметдинов, Миңнебай Габдрахманов (Диния нәзарәтеннән Иске Яхшый авылына эшкә җибәрелгән), Мифтах Сәләхов кебек хәзрәтләрне яхшыйлылар бик җылы сүз белән искә ала. Ул вакытта эшләгән җитәкчеләр мәчетне ябу өчен күп тырышлык салалар. Ләкин Иске Яхшый авылы халкы бик уңган, алар мәчетне яптыру ягында булмый. Беренче һәм Икенче Бөтендөнья сугышында катнашкан, батыр, бернәрсәдән дә куркып тормаган авылда бригадир да, ындыр табагы мөдире дә булып эшләүче Хәлиулла Нәбиуллин бик актив кеше булуын әле дә сагынып сөйлиләр авылда. Бер мәлне ниндидер сәбәп белән КПСС райкомына керә. Секретарь аны күреп кала һәм кабинетына чакыра да әйтә: «Мәчетне кайчан

ябасыз инде» ди. Тегесе исә: «Ябалар, ябалар. Әле тактасы черек, мәчет йортына кертеп өйделәр инде», – дип җаваплый. Һәм шул җавабы өчен бер гаепсезгә аны партия әгъзалыгыннан чыгаралар. Бу хәбәр тирә-якка тарала. Шуннан соң мәчетне ябу турында сүз булмый…

1990–1994 елларда мәчет белән Хәлимулла Мортазин җитәкчелек итте. Ул елларда мәчет бинасы бик таушалган була. 1991–1992 елларда Үзәк Диния нәзарәтеннән җибәрелгән Миңнебай хәзрәт Габдрахманов имам эшен башкара, ә 1992 елдан Динислам Садрислам улы эшли. 1993–1994 елларда Хәлимулла оештыруында, халыкның тырышлыгы белән һәм хуҗалыкара урман хуҗалыгы начальнигы булып эшләүче Фәметдин Галиәкбәров агач материалы белән ярдәм итеп, манара һәм мәчет түбәсе өлешчә яңартыла. Хәлимулла таш баганалар утыртып икенче мәчет урынын да киртәләп калдыра. Вакыт үтү белән һәрнәрсәне яңарту, ныгыту таләбе куела.

2008 елда Балтач муниципаль район хакимияте башлыгы Галләмов Рәфил Әмин улының тырышлыгы, «Россельхозбанк» җитәкчесе Исламов Рәшит Тәрәкый улының, район оешмалары һәм аерым шәхесләрнең матди ярдәме белән Иске Яхшый мәчетенең түбәсе, тышлавы тулаем яңартылды, манара ныгытылды. Өч гасырга якын хезмәт иткән мәчет заманча төс алды.

Иске Яхшый авылы мәчете БР Мәдәният һәм милли сәясәт министрлыгы, Мәдәни мирасны күчемсез мирас объектларын саклау һәм файдалану баш идарәлеге тарафыннан XVIII гасырның архитектура һәйкәле булып танылды һәм Башкортстан Республикасының саклана торган объектлар реестрына кертелде. Шулай итеп, мәчетнең эшли башлавына 272 ел вакыт үткән. Аллаһка шөкер, бай тарихлы мәчеттән бүген дә азан тавышлары яңгырап тора.

ШТӘНДЕ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ





Әхвәз хәзрәт Габделхаков.

Авылның үз мәчетләре, мәдрәсәләре булган. Иң беренче Илекәй авылыннан килгән Габденнасыйр мулла имам-хатыйб булып үз вазифасын үтәгән. Аннан соң Иске Казанчыдан Ризван хәзрәт имамлык эшен дәвам иткән. Ул 1894 елда вафат булган. Кабер ташындагы үлгән елы сакланган, димәк, 116 ел аның вафатына. Штәнде авылында 54 еллап гомер иткән. Шул дәвердә ул бик күп шәкертләр, мулла-мөәзиннәр, хәзрәтләр укытып чыгарган. Мәдрәсә зур булган, тирә-як авыллардан, районнардан да укучылар күп укый анда. Ризван хәзрәт мәрхүм булгач, аның эшен улы Лотфулла дәвам иттерә. Туйкаштан килгән Гайнельян хәзрәт тә монда укыта, биредә вафат булган.

Авыл мәдрәсәсендә үзебезнең укып чыккан мулла-мөәзиннәребез, хәзрәтләребез күп булган. Мәсәлән, Шәйсолтан улы Җиһангир хәзрәт дин галиме (Колый авылында), Балтачта имам-хатыйб булып күп еллар эшләгән. Кабере Иске Балтач зиратында. Габделхак Гарифулла улы мулла-мөәзин, мөгаллим була, күп шәкертләр укыта, күп еллар имам-хатыйб, указлы мулла, хәзрәт булып, 1975 елда вафат булганга кадәр дин юлында була.

Әхвәс Габделхак улы истәлекләреннән: «Мәчетнең манарасын кисеп, соңыннан сүтеп алсалар да, кеше өендә жомга намазлары, гаетләр укыйлар. 1930 елда әтием Габделхакны дин тота дип, йорттагы булган бар мөлкәтләрне конфисковать итеп, үзен кулга алдылар».

Габделхак бабай ике ел төрмәдә, биш ел сөргендә булып кайта…

1984 елда авыл аксакаллары әтиеңнең эшен дәвам ит, дип дини оешма эшен алып баруны Габделхакның улы Әхвәскә тапшыралар.

Яңа мәчет булдыру турында сүз алып барыла башлый. Якташлары Сөләйманов Айрат Рәис улы авылда иман йорты булдыруда зур ярдәм күрсәтте. Бүгенге көнгә мәчетнең эчке эшләре генә калды. Тиздән бу мәчет тә ачылыр, азан тавышлары яңгырар, намазлар укылыр, иншәаллаһ!



Штәнде авылы зиратындагы кабер ташы «Остазым Ризван Ибн Абдулла, 1894 ел» дип язылган

ИСКЕ ЯНБАЙ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

Иске Янбай мәчете алдында.



Имам-хатыйб Тәхәбиев Факетдин Тәхәби улы. 1958 ел.

Иске Янбай авылында, 1905 еллардагы мәгълүматлар буенча, 200 йорт һәм 1398 кеше исәпләнгән. Авылның ике мәчете, мәдрәсәсе, тимерлеге, буяу-ману остаханәсе булган.

Авыл урта хәлле тормыштан гыйбарәт. Мәчет-мәдрәсәнең, муллаларның йогынтысы бик зур булган заманында. Фәесхан мулла бик укымышлы кеше була. Әмма аны кысырыклагач, авылны ташлап чыгып китә. Шәйхетдин мулланы да кулаклаштыралар. Аның Әхияретдин һәм Борхаметдин исемле ике улы да мулла булганнар, өченче улы – Зыя исемлесе – сугышта үлгән.

Авылның иң олы кешесе, 97 яшьлек Гыйлемҗанов Гыйльмисолтан бабай истәлекләреннән: «Иске Янбай авылыннан Әбелкарам исемле кеше Өрдәгеш, Тушкыр авылларында мулла була. Вәсфи исемле мөәзин һәм Солтангир, Давыт муллалар да заманында динне алга иткән, дип сөйлиләр. Дин йогынтысы ул елларда бик көчле булган, дин кануннарына, муллаларга халык буйсынып яшәгән».

Авылдагы беренче мәчет хәзерге Иске Янбай мәктәбе урынында, ике катлы агачтан булган. Замана шаукымында манарасын кисеп мәктәп, китапханә, ашханә итеп файдаланганнар.

Икенче мәчет югары оч урамында урнашкан. Аның манарасы киселмәгән булган, шулай ук ике катлы агачтан була. Мәчетне балалар бакчасына әйләндергәннәр, ләкин ул озак эшләмәгән. 1937 елда янгын чыгып, мәчет янып китә. Бу ике мәчетне муллалар һәм авыл халкы бергәләп төзегән булган. Бигрәк тә авыл картлары төзүдә иң актив катнашалар. Шәймәрдән, Хаҗиулла, Факаетдин, Шәйхетдин, Фәюрша, Тәкбурша, Хәбип, Әхәт исемле муллаларны һәм бабайларны хәтерлиләр.

1876 елдан 1958 елга кадәр авылда Факаетдин Тәхәбиев мулла вазыйфасын алып барган. Аннан соң, олылар сөйләве буенча, Гайфулла Гайфуллин, Хәмәтнур Җиһангиров, Солтанша Шәймәрданов, Гыйльмисолтан Гыйлемҗанов бабайлар, хатын-кызлардан Габидә Мирхәйдарова, Хәмидә Шакирова, Фатыйма Шәймәрданова, Хәлимә Бадамшина һәм Фәрхиҗинан Кашапова әбиләр остабикә булып халык арасында дин һәм мәгърифәтчелек



Вафий Амири хәзрәтләре.

йолаларын үтәп, хөрмәтле, миһербанлы, изге күңелле шәхесләр булып, авыл халкының хәтерендә сакланалар...

Элекке мәчетләр яныл, тузып беткәч, авылда яңа мәчет салынмаган. Мәчет булмаса да, авыл халкы динле булган. Еш кына гает бәйрәмнәрен Зөлкәбирә әби өендә һәм элеккеге мәчет урыннарында үткәргәннәр. Хәзерге вакытта да еш кына дини мәҗлесләр Рания һәм Рәвис Акамовлар өендә үтә. Коръән мәҗлесләрен үткәрүдә авылдашларына Бәһиҗә Кәбир кызы Гыймранова ярдәмләшә, Аллаһы Тәгалә савап насыйп әйләсен.

1969–1970 елларга кадәр янган мәчет урыны буш торган. Шул елларда бу урынга балалар бакчасы төзелә һәм ул, 2002 елларга кадәр эшләгәннән соң, ябыла. Шул дәвер эчендә буш торган Гыльминиса Гыйрфанова әбинең өе мәчет вазыйфасын үти. 2005–2006 елларда халык җыенында авылда мәчет турында да сүз кузгатыла.

Халык соравын канәгатьләндереп, ябылган балалар бакчасын район Советы карары белән мәчет итеп файдаланырга рөхсәт ителә. Мәчетне торгызу, яңарту, төзекләндерү эшләрен башлап йөрүче итеп Мөдәррис Нәзгать улы Шакиров тәгаенләнә.

Авыл халкы күмәкләшеп өмәләрдә катнаша башлый. Һәм мәчетнең түбәсен буяп, йөзләп куялар. Мәктәп укучылары һәм олылар белән бергәләп, мәчет тирәли агачлар утыртыла. Мәчет эчендә намаз уку, гыйбадәт кылу өчен шартлар тудырылган, хатын-кызлар өчен дә аерым бүлмә булдырылган.

Мәчетне торгызуда хәләл көчләрен сарыф иткән, матди ярдәм күрсәткән кешеләр байтак. Мәсәлән, Рәшит Фәйрушин, Риф Нуртдинов, Рәмил һәм Мәгъдән Әхәтовлар, Рәшит Галиев, Гаделкарам Кабулов, Зәки Шәймәрданов, Мәлик Тәгърифуллин, Фазылҗан Корбанов, Миңнегәгыйм Карапов, Радик Шакиров һәм башка бик күпләр. Мәчеткә акчалата да ярдәм күрсәтүчеләр күп булды: Мәсидә Корбанова, Мәлик Тәгърифуллин, Гыйльмисолтан Гыйлемҗанов, Фәния һәм Мөдәррис Шакировлар, Мөдәррис Тагиров, Ришат Нуртдинов, Хәйрә Җиһангирова һәм башкалар. Гыйләҗев Илшат мәчеткә манара эшләп куйды.

Сания Сәрвәртдинова 2008 елда хаҗ сәфәрендә булып, мәчеткә дисбе һәм намазлыклар алып кайтты.

Мәчеттә гает намазлары укыла. Фазылҗан Билал улы Корбанов, Тәфгилә Фәтхиабрар кызы Галиханова, Роза Нәсгать кызы Корбановалар Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен, Ислам дине буенча яшәргә тырышлык итәләр, дин вә йолаларны намус һәм изге күңел белән башкаралар.

Авыл аксакалы, сугыш һәм хезмәт ветераны Гыйльмисолтан Гыйлемҗанов бабайга Аллаһы Тәгаләнең һәм авыл халкының рәхмәтләре яусын. Олы яшендә булуына карамастан, авыл халкына изге теләктә һәм фатихада тора.

ТҮБӘН СИКИЯЗ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Мәчет ачу тантанасы. 1994 ел.

Ничә дистә ел элек кенә манараларын кисеп, мәчетләрне мәктәп, идарә, мәдәният учаклары иткәннәр, яки күчереп салганнар. Еллар үтү белән халык ата-бабалардан калган диннән ваз кичеп, еракка китеп булмаганын аңлады. Әйе, тарихта да үткәннәрсез киләчәк булмаганы билгеле.

Мәчет ачу тантанасында уңнан сулга: Тәтешле мөхтәсибәте имам мөхтәсибе Мөхәммәтгали хәзрәт, Дүртөйле мөхтәсибәте имам мөхтәсибе Рамиль хәзрәт, Башкортстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәммәт хәзрәт Нигматулла, район хакимияте башлыгы Рәшит Исламов, Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт һәм «Сигнал» күмәк хуҗалык рәисе Мәкъсут Фагамов.

1994 елның кышкы чатлама суык декабрь аеның бер җомга көнендә Түбән Сикияз авылында мәчет ачу тантанасы үткәрелде.

Бу авыл тарихы, гореф-гадәтләре белән бик бай. Үткәннәргә күз салсак, элек биредә ике мәчет һәм югары оч мәчете янында мәдрәсә эшләгән. Аларның язмышы да башкаларныкыннан аерылмый. 1908 елда авылда беренче мәчет төзелә. Мулла итеп Хәлимҗан хәзрәт үзенең йортында мәдрәсә оештыра. Шәкертләрне Хәлимҗан хәзрәтнең улы Кәшфелгаян һәм Миңнегариф хәлфәләр укыта. 1909 елда кызлар өчен мәдрәсә эшли башлый. Аларны Хәлимҗан мулланың остабикәсе укыта. 1914 елга кадәр авылда бер мәхәллә була. Халык динле, барсы да мәчеткә намазга йөри, шуңа да икенче мәчет төзү мохтаҗлыгы туа. Һәм шул ук елда авылның икенче очында мәчет салына. Монда мулла булып 25 яшьлек Фәйзелхак Җиһангиров, мөәзин итеп Сәрвәртдин Гыйльметдиновлар сайлана. Шулай итеп, авылда ике мәчет була. Шул ук елны икенче мәчеттә дә мәдрәсә ачыла. Мәдрәсә Сәрвәртдин мөәзин йортына урнаша. Мулла белән мөәзин укыта, укырга икенче мәчет балалары килә. Беренче мәчетнең имамы Хәлимҗан хәзрәт вафат булгач, аның урынына дини гыйлемле Җиһанша хәзрәт эшләп китә. 1920 елның җаенә кадәр Түбән Сикияз авылында уку-укыту эше дин нигезендә алып барыла. Шушы ук елда совет органнары авылга беренче укытучыны җибәрәләр. Ул муллаларны мәчеттә һәм мәдрәсәләрдә укытуны тыеп, үзе укыта башлый.

Имам-хатыйб Вәсил Газизов.

1922 елда икенче мәхәллә имамы Фәйзелхак мулла кулга алына һәм сөргенгә озатыла. Аның урынына имам итеп Зыяфетдин куела. Ләкин ул да берничә ел эшләгәннән соң сөргенгә җибәрелә.

Монда хәзрәт булып эшләгән Сәрвәртдин ага чит якларга чыгып китә. Вакыт узу белән ул янә туган ягына кайта. Олы яшьтә булуына карамастан, агачына җил, су тимәсен дип, мәчетне үз куллары белән тышлый.

1938 елга кадәр төрле муллалар алышынып, мәчетләр эшләп килә. Ләкин бу елда югары һәм түбән мәхәллә мәчетләре ябыла, манаралар кисеп төшерелә. Мәчетләрнең берсендә мәктәп, икенчесендә изба-читальня (китапханә) эшли башлый. Шушы елны беренче мәхәллә мәчетен сипләп күтәреп, мәктәп

Түбән Сикияз мәчете әхелләре.

бинасы итеп төзиләр. Һәм ул 1998 елга кадәр тора. Яңа мәхәлләләр оешканчы авылда мулла вазыйфасын Зәгафуран Әсләмов, Габдулла Нурмөхәммәтов, Гайнелҗан Хәсәновлар башкара…

Иман нурын чәчкән, яшәүнең мәгънәсен ачыклаган мәчетнең кирәклеген авыл халкы яхшы аңлый. Аларның фикерен район хакимияте башлыгы, авылдашлары Рәшит Исламов, «Сигнал» колхозы рәисе Мәкъсүт Фагамов, авыл Советы рәисе Муллахмәт Хәйретдинов хуп күрә. Колхоз балансындагы кунакханә өчен төзелгән бинаның ике бүлмәсен мәчет өчен куллануга бирергә, дигән карар чыгарыла. Шушы бүлмәләр ремонтлана, җиһазлана, михраб, мөнбәр төзелә. Манараны Уфадан Хәлимҗан Ногманов проекты буенча эшләтеп, алып кайтып урнаштыралар. Гомумән, мәчеткә байтак көч салына, ярдәм ителә. Авыл картлары мәчеткә һәр җомга саен йөри башлый. Шуңа күрә дә авыл халкы өчен аны ачу тантанасы көтеп алынган бәйрәм була. Мәчет ачу мәҗлесендә Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров иң элек килгән кунаклар белән таныштырып үтте. Бирегә Башкортстан Диния нәзарәтеннән, Дүртөйле, Тәтешле районнарыннан, Агыйдел, Нефтекама шәһәрләреннән кунаклар килде. Районыбызда тагын бер иман йорты ачылуына Башкортстан радиосы һәм телевидениесе дә битараф калмаган иде. Алар бу сөенечле хәбәр белән республика мөселманнарын шатландырырга исәп тота. Шулай телевидениедән «Бүген җомга» тапшыруын алып баручы журналист Яркәй хаҗи Яхшыдәүләтов, «Иман» тапшыруын алып баручы журналист Сәләхетдин хаҗи Сукбаев та килгән иде.

Мәчетнең олылар белән яшьләргә аралашып яшәргә мөмкинчелек бирүе, яки кешедә табигать биргән сафлык кайтаруда әһәмияте чиксез булуын һәр чыгыш ясаучы билгеләде. Башкортстан Диния нәзарәте рәисе һәм мөфтие Нурмөхәммәт хәзрәт Нигъмәтулла, Тәтешле мөхтәсибәтенең имам-мөхтәсибе Мөхәммәтгали хәзрәт, Дүртөйле мөхтәсибәтенең имам-мөхтәсибе, Дүртөйле мәчете имам-хатыйбы һәм Нефтекама, Агыйдел шәһәрләре мәдәрәсәләрендә белем алган кунаклар авылда мәчет ачылуның әһәмияте хакында сүз алып барды. Мәчетнең имам-хатыйбы итеп Нефтекама мәдрәсәсендә белем алган Вәсил Газизовны мөселманнар бик ризалык белән билгеләп куйды.

2005 елда авылга яңа мәчет салдыру мәсьәләсе буенча киңәшләшергә авыл мәдәният йортында мәхәллә мөселманнары җыен җыя. Һәм бер тавыштан яңа мәчет төзергә дигән карарга киләләр.

Мәчет бинасы өчен Урта Елга авылындагы соңгы вакытта клуб булып торган борынгы мәчет бинасы кулланыла. Җыенның икенче көнендә үк төзелеш эшләре башлана. Төзелештә авыл халкы бердәм катнаша, өмәләр үткәрелә. Күмәк көч белән 5 ай эчендә мәчет сафка баса һәм 9 сентябрь көнне беренче җомга намазы укыла. Бу мәчетне төзүдә «Сигнал» хуҗалыгы рәисе Фирдинанд Назыйф улы Арсланов, авыл хакимияте башлыгы Марат Малик улы Габидуллиннар зур ярдәм күрсәттеләр.

Мәчеттә ислам дине йолалары башкарыла, дини бәйрәмнәр үткәрелә. 2006 елда мөәзин итеп Радик Гариф улы Газизов билгеләнде.

«НУР» МӘЧЕТЕ

Яңа Балтач авылында моннан унике ел элек мәхәллә оештырылып, авылга яңадан иман кайтты. Мәхәлләнең имам-хатыйбы Рәшит Хәмитов була. Биредә элекке фельдшерлык пункты бинасында дини йолалар башкарылып, ун ел хезмәт иткәч, манарасы булмау сәбәпле, 2005 елда корбан бәйрәменә кадәр иман йортына манара урнаштыруны максат иткән булганнар. Бу ниятне уйлаганнар изге бәйрәм көненә бурычлы калмады. Иганәчеләре дә, балта осталары, тимерчеләре дә шул ук авыл кешеләре булды. Мәсәлән, Татарстанда яшәүче якташлары, малтабар Гөлфирә Хөснуллина манараны йөзләү өчен табак калай булдыруда ярдәм күрсәтте, авылда яшәүче Рәшит Гайфуллин, Факия Нурисламова, Зәкия Зарипова, Фәнис Заһировлар акчалата ярдәм күрсәттеләр. Иганәчеләр һәм төзелеш эшләрен башкарган Фиат Фәтхинуров, Лотфый Фәтхлисламов, Рәфкать Нурисламов, Илфат Шәңгәрәев, Радик Нигъмәтҗанов, Руслан Ахунов, Малик Әхтәриевлар тырышлыгы белән 2006 елның яңа елы алдыннан мәчетнең мәһабәт манарасы калкып чыкты. Манаралы иман йортына «Нур» мәчете дигән исем бирелде. Әнә шулай итеп корбан бәйрәме көнендә авылда «Нур» мәчетен ачу тантанасы үтте.

Авылдагы «Нур» мәчетеннән күп еллар иман нуры сибелер, иншәаллаһ!

ЮГАРЫ КАРЫШ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Уңнан сулга: Шәхисултан хәзрәт Нигмәтулла, Әүхәди хәзрәт Шәхисултан. 1902 елда бояр Тельбиков төшергән фото.

Карыш авылы – Башкортстандагы мишәр-татарлар нигезләгән борынгы авылларның берсе. 1754–1755 елгы күтәрелеш житәкчесе буларак тарихка кереп калган, Башкортстан һәм Русия мөселманнары өчен изге эшләр башкарган Габдулла Галиев Батырша хәзрәт чыгышы белән шушы авылдан.

Авылда беренче мәчетне 1702–1705 елларда Туктаргали мулла төзеткән.

Исет провинциясендә имам һәм мөдәррис булып эшләгән Батырша хәзрәтнең авылдашлары килеп, авылга имам булып кайтуын үтенәләр. Батырша хәзрәт теләп ризалаша һәм 1749 елда Карышбашка кайтып эшли башлый. Карышбаш авылында әтисенең бушап калган өен мәдрәсә итеп, балалар укыта башлый, мәчет төзелешен дә алып бара. 1750 елда мәчет һәм аерым мәдрәсә бинасы, шәкертләр өчен гомум торак төзү эшләре тәмамлана. 1755 елда ул кулга алына.

Кызганычка каршы, Батырша хәзрәттән соң авылда кем имам булуын белә алмыйбыз. 1834 елда үткән ревизия мәгълүматларына караганда, беренче указлы мулла Фәхретдин Гобайдуллин, икенчесе – Котлыәхмәт Гобайдуллин, өченчесе – Әбделгани Мөхәммәтрахимов (Гомәров) булган.

Батырша хәзрәт төзеткән мәчет бик иске булганлыктан, Әбделгани хәзрәт аны яңадан сала. Батырша хәзрәт мәчетне нәкъ елга ярына төзеткән булса, Әбделгани хәзрәт мәчетне авыл эченәрәк, 100–150 метрлап көнчыгышка күчертеп сала. Бүгенге көндә ул мәчет урынында су башнясы утыра.

Әбделгани хәзрәт үзенең өен дә мәчеткә якын итеп төзетә. Аның эшчәнлеге турында буыннан-буынга сөйләнеп, безнең көннәргә кадәр килеп житкән риваятьләр сакланган. Зур укымышлы, халыкның терәге булуы белән бергә, халык медицинасын да яхшы белүен бәян итәләр иде. Ул көчле

Уңнан сулга: Хөсәинов Лотфирахман Хөсәин улы һәм Гаитов Шәхисултан Әүхәди улы (1961 ел).

Мәләви хәзрәт Шәхисултан улы Гаитов.

Имам-хатыйб Гомәров Әхмәтнәби Шакирҗан улы, имам-хатыйб Солтанов Мөтәхәр Әухәди улы, имам-хатыйб Бәләгытдин Әхкәмов.

гипнозга да сәләтле булган. Теге яки бу авырудан, бигрәк тә авырлы хатыннар кыш урталарында ниндидер җиләк-җимеш ашыйсы килеп, аңа барганнар. Хәзрәт дәвалаганнан соң «Рәхәтләнеп, туйганчы ашадым», дип әйтә торган булганнар. Әбделгани хәзрәт бик бай кеше булган. Гомеренең соңгы еллары якынайганын сизеп, гаиләсенә, балаларына байлыгын гадел итеп бүлеп биреп, икенчегә хаҗ сәфәренә чыгып китә һәм анда берничә ел яшәп, хаҗ гамәлләрен үти, бу яклардан барган хаҗилар артыннан гаиләсенә, туганнарына сәламнәрен җиткереп тора. Ул Мәккә шәһәрендә дәфен кылына.

1830 еллар тирәсендә Батырша хәзрәт төзеткән мәдрәсә дә яңартыла, монда балаларны Фәхретдин мулла укыта.

Әбделгани хәзрәттән соң Котлыәхмәт Биктимеров, Мәүләви, Фәйрүз, Әхсән исемле кешеләр мулла булып торганнар.

1830 елларда авылда икенче мәхәллә мәчете төзелә. Анда беренче указлы мулла Фәхретдин, икенчесе – Котлыәхмәт

Имам-хатыйблар: Мәүлетов Мәкътип Лотфирахман улы һәм Хаҗиев Наил Мәгафур улы.

Гобайдуллиннар булган. Ә 1868 елда Диния нәзарәтенең тәкъдиме буенча, авыл халкы имамлыкка Караидел районыннан Шаһисолтан Гаитовны чакыралар. Аның тәкъдиме белән 1872 елда яңа мәчет төзелә, шунда ук мәдрәсәсе дә була. 1890 елда Шаһисолтан хәзрәт, сәламәтлеге какшау сәбәпле, имамлыкны Шакирҗан хәзрәт Әхмәтша улына тапшыра, аның бертуган энесе Закирҗан мөәзин вазыйфасын башкара. 1918 елда Шакирҗан һәм Закирҗан Гомәровларга авылны калдырып китәргә туры килә һәм аларның язмышы аянычлы була.

Мәчет төзелешендә сулдан уңга Мансуров Рамил һәм Такиуллин Илдус.

1918 елдан мәчетнең имамы итеп Әүхәди Шаһисолтан улы Гаитовны сайлыйлар. 1933 елда ул 3 елга сөргенгә җибәрелә.

1934 елның сентябрь аенда беренче мәчетне ябып, культура йортына әверелдерәләр, икенчесен 1935 елда мәктәпкәчә яшьтәге балаларны тәрбияләү өчен бина итеп бирәләр. Тарихи чыганакларга караганда, мәчетләрне закон нигезендә файдалануга тапшыру өчен 1934 елның 10 сентябрендә һәм 1935 елның 26 февралендә, мәчетләр файдаланылмый тормасын дип, җыелыш җыеп, карар чыгарып, хәл итәләр. Җыелышларның һәрберсендә катнашкан 140–180ләп кешенең күбесе бу тәкъдимгә риза була, тик берничә авыл карты мәчет шул хәлендә торсын, дип каршы чыгалар.

Сугыштан соңгы еллардан алып бүгенге көнгә кадәр туган балаларга исем кушу, мәрһүмнәрне соңгы юлга озату, никах уку, Коръән мәҗлесләрен үткәрү һәм башка йолаларны Лотфирахман бабай Мәүлетов, Фәтхлислам Шәйхлисламов, Әхмәтнәби Гомәров, Мәкәтип Мәүлетов, Бәләгытдин Әхкамовлар үтәп киләләр.

2004 елдан башлап дин эшләрен Хаҗиев Наил Мәгафур улы үти башлады.

1993 елда авылда яңы мәчет төзелә башлый. Нигез ташларын

сатып алу өчен район хакимияте башлыгы Исламов Рәшит Тәрәкый улы, «Октябрь» күмәк хуҗалыгы рәисе Сибатов Рәис Хәсән улы матди ярдәм иттеләр. Мәчет төзүдә төп матди чыгымнарны Габбасов Ансар Әсләм улы үз өстенә алды. Тиздән Югары Карыш авылында да азан тавышлары яңгырар.

Карышбаш мәчетенә ай кую тантанасында, сулдан икенче Габбасов Ансар Әсләм улы.

«НӘВИЛӘ» МӘЧЕТЕ



Кем төзеткән Аллаһ йортын
Ходай бирер савабын,
Авыл күңеле нурланыр,
Тыңлап азан авазын.
«Кызыл давыл» кырган манаралар
Күтәрелә бүген биеккә.
Кысаларда калган хак динебез
Тар читлектән чыкты иреккә.

Манарада күккә менгән айдан
Мөселманның күңеле нурлана,
Гамәлләре игелек-изгелек белән,
Шәфкатьлелек белән зурлана.
Бакыйлыгың торсын күз алдында
Яшәгәндә фани дөньяда,
Уйлан, игелекле синең гомерең,
Кешеләргә синнән ни кала?

Уразай авылы мәчетенә нигез салу тантанасы. 2006 ел.

Мәчет төзелешендә. 2007 ел.

Бөтендөнья Дәүләтләр Берлегенең Себер һәм Европа илләре Үзәк Диния нәзарәте рәисе, баш мөфти Тәлгать Таҗетдин мәчет ачу тантанасы белән тәбрик итә.

Башкортстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәммәт Нигъматулла мәчет ачу тантанасы белән тәбрик итә.

Асфальт юллардан гына жилдереп Иске Уразай авылы аша үткәндә әллә каян күзгә ташланган заманча архитектуралы нурлы мәчет яныннан узасың. Ул «Нәвилә» мәчете. Таш мәчет авылның олы юл өстендә калкып чыкты. Бирегдән районның 10нан артык авылына юл уза.

Дилмиев Нурихан Шәмсилбаян улы мәчет ачу тантанасы белән тәбрик итә.

Пәйгамбәребезнең бер хәдисендә: «Юмарт кеше Аллаһыга, кешеләргә вә җәннәткә якын, җәһәннәмгә ерак булыр», диелгән.

Якташлары, Нефтекама шәһәрендәге чикләнгән җаваплылыктагы «Нефтегазстрой» җәмгыяте җитәкчесе Нурихан Дилмиев үз хисабына төзетте аны. Әнисе рухын шатландырып мәчеткә «Нәвилә» исеме бирелде.

Уразай авылы 1500–1550 елларда нигезләнгән. Авыл барлыкка килгәч, беренче мәчет төзелә, ә инде 1900 елларга авылда өч мәчет була. 1937–1938 елларда мәчетләр ябыла, аны клуб һәм мәктәп итеп файдалана башлыйлар.

Районда бер-бер артлы дип әйтерлек гыйбадәт йорты сафка бастырыла башлый.

Дилмиевлар да бер шулай туган йортларына кайткач, бөтен нәсел-нәсәпләре белән жыйнаулашып сөйләшкәннән соң, бу изге-уй ниятләрен тормышка ашыра башлый. Мәчет бик күркәм урында булырга тиеш, карты да, яше дә бирегә үз теләкләре белән килерлек булсын, дигән фикерне куя алар.

Ике ел эчендә Аллаһ йортында дини йолалар башкарылырга әзер иде инде.

Мәчетнең архитектурасы бик матур, ул үзе бер комплекс тәшкил итә. Тирә-ягына агачлар утыртылган, асфальт сукмаклар түшәлгән.

Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы вәкиле, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, композитор Лукманов Алик Харис улы мәчет ачу тантанасы белән тәбрик итә.

Мәчетнең идән асты өлешендә ике уку классы, өстәге катында хатын-кызлар өчен намаз залы бар. Имам-хатыйб өчен аерым эш бүлмәсе каралган. Ирләр һәм хатын-кызлар залларына керү урыннары аерым-аерым.

Аны ачу тантанасы 2008 елның октябрь аенда үткәрелде. Бу изге бәйрәмдә Бәйсез Дәүләтләр Берлеге, Европа өлеше, Себер һәм Балтыйк илләренең Үзәк Диния нәзарәте рәисе, баш мөфти Тәлгать Сафа улы Таҗетдин, Төркиядән Ягафәр Садыйк, Башкортстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәммәт Нигъмәтулла, Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров, БР Дәүләт Җыелышы – Корылтай депутаты Ринат Нәбиев, муниципаль район хакимияте башлыгы Рәфил Галләмов һәм башка бик күп кунаклар катнашты.

Ул көнне изге бәйрәмгә җыйналган мөселманнар гаҗәеп күренешкә тап булды. Баш мөфти Шәйхелислам Тәлгать Таҗетдин ясаган чыгышында җыйналган халыкның игътибарын аяз зәңгәр күк йөзендә бер якта кояш елмаюы, икенче якта тулы ай һәм салават күпере барысы берьюлы пәйдә булуын әйтте. Халык бу могҗизаны Аллаһы Тәгаләнең мөселманнар белән бергә шатлану билгесе итеп кабул иттеләр. Районыбызның һәвәскәр шагыйре, сугыш һәм хезмәт ветераны, берничә китап авторы Әхнәф Мазһаров күңелендә бу күренеш шигырь юлларына салынды.

Ул көн кояш белән бергә
Нур балкытты көмеш ай,
Тәңребез иман йортына
Фатиха бирде шулай.
Уян, авыл, уйлан, авыл,
Хак юлың синең кайда?
Кил мәчеткә, гыйбадәт кыл,
Жаныңа эзлә дәва!

Ай, кояш бергә балкыды
Мәчет ачылган мәлдә,
Хак юлына кире кайта,
Иншалла, хәзер бәндә.
Нур балкыта Уразайга
Көмеш айлы манара,
Кайтара иман юлына
Хәзер яңа замана.

Изге бәйрәмдә баш мөфти «Нәвилә» мәчетенә ислам диненең байрагын тапшырды.

Иске Уразай авылындагы «Нәвилә» мәчетенең имам-хатыйбы итеп чикләнгән җаваплылыктагы «Уразай» җәмгыяте директорының тәрбия эшләре буенча урынбасары Фәрит хәзрәт Әрхәметдин билгеләнә. Хәзерге вакытта мәчеттә балалар һәм өлкәннәр төркемнәре өчен дин дәресләре бирелә, 5 вакыт намаз укыла. Җирле «Уразай» күмәк хуҗалыгы да авылда дини тәрбияне көчәйтүгә үз өлешен кертә: имам-хатыйб Фәрит хәзрәт Әрхәметдин хуҗалык штатында җитәкченең тәрбия эшләре буенча урынбасары. Һәм ул фәкать тәрбияви, дини эшләр белән генә шөгыльләнә. Фәрит хәзрәт Уфадагы Р. Фәхретдин исемендәге ислам институтын читтән торып тәмамлады.

Уразайда яшәүче шагыйрә җанлы, динне ихтирам иткән Ания Арсланова авылдашлары исеменнән бу изге бүләккә шатлану хисен белдереп «Мәчетле булдык» дигән шигырен язды.

Мәчетле булдык

Мәчетле булды Уразай,
Мәчеткә кунды бу ай,
Дингә дә кайтабыз бугай,
Гомерләр бирче, Ходай.
Нуриханга мең рәхмәт
Бу хәтлем бүләгенә.
Тормышка ашсын теләге
Ни генә теләсә дә.
Авыл халкы дингә кайтсын
Яхшы фикерләр белән.

Бердәм дуслар булып яшик
Авылыбыз халкы белән.
Нинди матур безнең мәчет,
Тирә-юньдә юк андый.
Сокланып карап торамын
Күзләремне дә алмый.
Азаннары яңгырап торсын
Уразайга ямь өстәп.
Дога-фатихалар биреп,
Бәхет-шатлыклар теләп.

«ЯҢА ТОРМЫШ» МӘЧЕТЕ



Имам-хатыйблар: Хәтмуллин Гайфулла һәм Өмәтдинов Фәйзелгаян.

Заманында Түбән Карыш авылында өч мәчет булган.

Рәфига Хәкимҗан кызы Гайнетдинова истәлекләреннән чыгып шуны әйтергә була: Түбән очтагы мәчеттә Мөнир һәм Галинур исемле кешеләр мулла булып торганнар. Мөнир Ногман улы мәчеттә шәкертләр укыткан. Урта төбәк мәчетендә Гайнетдин улы Суфияр мөәзин була. Ул бик тырыш һәм батыр кеше була. Мәчетне сүтеп алгач та, шул урында кешеләр җыеп, дини йолалар башкаруны дәвам иттерә.

Югары оч мәчетен Фәйзелгаян дигән кеше салдыра. Анда үзе һәм Шәйхлислам мулла булалар. Фәйзелгаян бик бай була. Эшчеләре аны ихтирам итә, ярата. Мулла үзе дә аларга карата яхшы мөгамәләдә була. Аны сөргенгә җибәрмәү өчен зур тырышлык салалар, тик саклап кала алмыйлар, гаиләсе белән сөргенгә җибәрелә һәм шунда гаеп була.

Туып-үскән авылында мәчет төзетүне ният итеп алган Ринат Нәҗип улы Галимовны да киң күңелле шәхес дип әйтергә нигез бар. Ринат гаиләсе белән ерак Себердә 11 ел яшәгәннән соң, Уфа шәһәренең Суровка авылына кайтып төпләнә. Туып-үскән авылында гыйбадәт йортын төзүне ният итеп куя, тормыш иптәше Рәфидә Тимерхан кызы исә бу изге ниятен хуплый гына. Гомумән, алты бертуган изге эшкә бердәм кушыла.

Яңа мәчетне ачу тантанасы 2008 елның 9 июль көнендә, яки мәрхүм әтиләре Нәҗип Зыятдин улының вафатына 31 ел тулган көнне үтте. Биредәге олуг мәҗлестә катнашып, чыгыш ясаучылар Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров, район хакимияте башлыгының социаль

Түбән Карыш авылы мәчетен төзетүче Ринат Нәҗип улы Галимов гаиләсе белән.

Мәчеттә беренче азанны Аскын мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Сәлмән хаҗи әйтте.

Мәчет ачу тантанасында Хәмзә хәзрәт һәм район хакимияте башлыгы урынбасары Фирдәвис Рәхимов.

Түбән Карыш авылы мәчетендә Мәүлид бәйрәме. 2009, март.

мәсьәләләр һәм кадрлар буенча урынбасары Фирдәвис Рәхимов, авыл Советы Авыл биләмәсе башлыгы Наил Җиһаннуровлар Ринат Нәҗип улы Галимовка, туганнарына, мәчетне газлаштыру эшен үз исәбенә башкарган (житәкчесе Ринат Сәхапов) «Газсервис» җәмгыятенә, «Сельэнерго» җәмгыяте (Зәбир Сәрвәртдинов) ярдәме белән электр үткәрү эшләрен башкарулары өчен зур рәхмәт белдерде. «Яңа тормыш мәчете» белән авылга иман кайтып, даны еракларга таралуын теләделәр.

БИГЕЛДЕ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Имам-хатыйб Сәрвәртдинов Миннекарам Сәрвәртдин улы.

Бигелде авылында мәчет 1870 елда төзелә. Ике катлы мәчет бик зур була. Авылда ул елларда 67 йорт исәпләнгән һәм анда 394 кеше яшәгән. Мулла Гайнулла улы Мөхәммәт Сафи , мөәзине Сәрвәртдин Фәрхетдин улы була. Ул 1928 елда сөргенгә җибәрелә.

Бүген дә халык телендә йөргән Бигелде мәчете 1898 елда салынган (монысы бәлки икенче мәчет булгандыр). Гомумән, 1905 елда авылда мәчет тә, мәдрәсә дә була. Чөнки бу төбәктә мәгърифәтле кешеләр борынгы заманнарда ук яшәгән. Мәчетнең аяныч язмышы 1930 елда хәл ителә. Нәкъ шушы елны СССР Халык Комиссарлары Советы Үзәк Башкарма комитеты (ВЦИК) белән берлектә 8–10 яшьлек балаларны мәҗбүри башлангыч мәктәптә укыту турында карар кабул итәләр. Шушы максатта һәр авылда башлангыч мәктәп ачу бурычы куела. Әмма моның өчен матди җирлек булмый. Мәктәпне кайда урнаштырырга? Авылларда мәчет биналарын, байлар йортларын файдалану максатка ярашлы, дип табыла. Менә шулай итеп, мәчет бинасы мәктәп булып китә.

1934 елның август аенда аның манарасы кисеп төшерелә. Бу хакта шул авыл кешесе Шәмгыя Ситдыйк кызы Мөхәмәдиеваның бүгенгәчә сакланган кульъязмасына күз салыйк.

«...Җәйнең кояшлы, ямьле көне. Авыл кызлары урманга җиләк җыярга баралар. Савытларын тутыргач, төштән соң кайтырга чыгалар. Шул чакны аяз күктә кап-кара бер болыт хасил була, көчле җил чыга. Һәм карга йомыркасыннан да зуррак боз ява башлый. Алар җиргә төшеп бәреләләр дә, кирегә күккә таба бер-ике метр биеклеккә сикерәләр. Болыт ничек килеп чыга, шулай үтеп тә китә, боз яву туктый. Кызлар качып торган кибән астыннан чыгып, кайтып китәләр. Тик авылларындагы әллә каян күзгә ташланган мәчетнең манарасы күренми. Кызлар аптырашта кала. Нәкъ манараны кисеп төшергән чакта, боз яуган икән. Димәк, шулай кара көеп, күк елаган».

Бигелде авылы мәчетен төзүне оештыручы һәм матди ярдәм күрсәтүче Шәйбаков Илдус.

Мәчет салу өмәсе.

Мәчет салу өмәсе.

Ике катлы мәчетнең аскы катына клуб, китапханә урнаштырыла, өске каты өч класс бүлмәсенә бирелә. Аннан инде 1963 елда бина сүтеп алынып, үзгәртеп корыла. 76 ел мәчетсез яшәүгә карамастан, халык диннән ваз кичми. Авылның дин гыйлеменә ия кешеләре дә күп була. Мәсәлән, Гаян Сәрвәртдин улы, Сәгыйть Ризван улы, Кыям, Хәкимҗан, Нурихан, Динислам

бабайлар, Тутыя, Сафия, Җамал әбиләр дини яктан белемле булалар. Бүгенге көндә авылда Әнвәр Зиннәт улы Зиннәтов, Рәфисә Ситдыйк кызы Шәйбәкова һәм Мәсния Сафетдиновалар дини йолаларны башкаручылар буларак танылды.

2006 елның июнь аенда Бигелде авылында үткәрелгән «Саумысыз, авылдашлар!» бәйрәме авыл халкы өчен зур вакыйгага әверелде. Аны үткәрү өчен шушы авылда яшәүче Илдус Габдинур улы Шәйбәков башлап йөрде. Бәйрәмгә җирле халык һәм шушы авылда туып-үсеп, башка төбәкләрдә яшәгән барлык авыл кешеләре җыелды. Шулай, бергәләп авылдашлар, якташлар очрашкан чакта, авылда мәчет салу турында сүз кузгатылды. Моны шулай ук Илдус Шайбәков күтәреп чыга һәм барысы да бу тәкъдимне хуплый. Ябылган мәктәп бинасын сүтеп, шул урынга мәчет төзергә карар итәләр.

Авыл халкы сүтү өмәсендә актив катнашты. Һәм шул урынны тигезләтү өчен трактор әрҗәсенә төяп, 100дән дә артык йөк ташлы ак балчык ташылды. Аннан инде нигез кору эшләре башланды. 2007 елның 11 ноябре көнне нигезен салу өмәсе үткәрелде.

Гомумән, авылда мәчет төзүне Шәйбәковлар нәселе: әтиләре Габдинур, аның уллары Әнфис, Илдус, Данис һәм Әнисләр үз өсләренә алды һәм бу эш өчен бар көчләрен салдылар, матди яктан да үз хисапларына бар эшне башкардылар. Бу изге гамәлгә мулла, булачак имам Әнвәр Зиннәт улы Зиннәтов бик теләп кушылды. Аллаһы йортын төзү эшендә кем матди, кем үзенең көче, кем техника белән ярдәм күрсәтүчеләр күп булды. Җирне бораулау эшләрендә «Сельэнерго» җәмгыяте директоры Зәбир Сәрвәртдинов ярдәм итсә, Газнәви Гарәфи улы Мусин агач материалларын хәстәрләде.

Аллаһыга шөкер, әнә шулай итеп 76 елдан соң Бигелдедә яңадан иман йорты авылга нур биреп торачак.

Авылдашлар киңәше буенча, мәчетне элекке мәктәп бинасы урынына төзүне планлаштыралар. 2008 елның 25 мае көнне нигезен салу оештырылган иде. Бинаның стеналары кирпечтән күтәрелде, түбә астына материалларны ярдыруда авылдашлары Газнәви Мусин ярдәм итте, 2010 елның гыйнвар аенда мәчетнең манарасы куелды.

Иншалла, Бигелде авылының тау башына урнашкан Аллаһы йорты тиздән ишекләрен ачар, дигән өметтә калабыз. Бу изге эшкә бөтен авыл белән күтәрелгәч, иншаллаһ, Аллаһы йорты җәйге айларда ишекләрен ачачак.

«ХӘНИФӘ» МӘЧЕТЕ



Көмьязы авылы мәчетен төзүчеләр Нуретдинов Рубин һәм Нуретдинов Рафаил Фәттәх уллары.

Тарихи чыганакларга караганда, 1860 елларда Көмьязы авылында ике мәчет булган. Ике мулла һәм ике мөәзин халык арасында дин эшләре алып барган. Динне кысулар башлангач, әлеге культура йорты урынындагысын клуб иткәннәр.

Көмьязы авылында «Хәнифә» исемендәге яңа мәчет 2003 елда 13 июнь көнне файдалануга тапшырылды.

«Сабантуена кадәр бер атналык эше бар иде мәчетнең», – ди Рубин Нуретдинов, – Авылда «халык табибәсе» буларак танылу алган зур әнисе Хәнифә рухын шатландырып, мәчеткә аның исемен биреп, Рөстәм энекәш мәңгеләштерергә тәкъдим итте. Бәйрәмгә якташлар да кайтуын исәпкә алып, авыл сабантуен бер атнага соңрак үткәрергә уйладык. Ул көнне мәчетне ачу тантанасыннан соң бөтен авыл, бәйрәмгә кайтучылар авыл сабантуена киттек».

Тантанага халык бик күп җыелган иде. Аны Көмьязы авыл Советы муниципаль берләшмәсе башлыгы Рәфкать Даутов ачты һәм сүзне дин әһелләренә бирде. Иске Балтач мәхәлләсе мөәзине Рауф хәзрәт Сафин Коръән укыганнан соң, имам-мөхтәсиб Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров мәчет ачуга фатихасын бирде. Район хакимиятенең оештыру-контроль комитеты рәисе Гали Сәрвәртдинов үз чыгышында иман йортын ачу уңаеннан район хакимияте, хакимият башлыгы А. М. Мәгъзүмов исеменнән ихлас котлаулар җиткерде, мәчеткә бүләк тапшырды. Вәгазь тотучы һәркем мәчетнең күңелләргә иман нуры иңдерүдә, сафлыкка, инсафлыкка өндәүдә зур өлеш кертәчәгенә ышаныч баглады.

Рубин Нуретдинов тумышы белән Татарстан Республикасының Әлмәт шәһәреннән. Лаеклы ялга чыккач, тормыш иптәше Ракыя белән туып-үскән Көмьязы авылына кайтып төпләнәләр. Нуретдиновлар нәселе булдыклылыгы, уңганлыгы, тырышлыгы белән билгеле.

Көмьязы авылына Рубин абыйларына кунакка Әлмәттә яшәүче һәм шәһәрнең вице-мэры вазыйфасында эшләүче икетуган энесе Рөстәм Радиф улы Хәсәнов кайта. Ямьле табигатенә соклана, авылның тирә-ягы агачлар белән уратып алган булуы да әсир итә аны. Шулай бер абыйсына әйтә: «Авылыгызда мәчет юк бит абый, әллә җыйнаулашып үз хисабыбызга төзибезме?», – ди. Рубин абыйның Яр Чаллыда тимер-бетон әйберләр заводы генераль директоры урынбасары вазыйфасын башкарган бертуган энесе Рафаил һәм Нефтекамада электромонтер булып эшләүче Ринат энесе аның бу тәкъдименә берсүзсез ризалык белдерәләр. Бергәләшеп төзергә дигән карарга киләләр. Һәм материалларны кайтарта да башлыйлар. 2002 елның июнь аенда нигезе салына. Нигез салу өчен бар материалларны Рөстәм Хәсәнов кайтарта, стенасына керамзит блокларны Нефтекамада яшәүче Рубин абыйның кияве Радик Әдип улы Хәсбиев үзе алып кайта һәм башка материалларны да туплауда аның ярдәме зур була. Гомумән, авыл уртасында балкып утырган иман йорты төзелеше тәмамланганчы, акчалата ярдәмне Рөстәм Хәсәнов күрсәтә, мәчетнең тышын йөзләү өчен кирпеч белән шул авылда туып-үскән, Уфа шәһәрендә эшләүче Әлфрит Йосыпов кайтарта, түбәне калай белән яптыру эшен бу эш остасы, төзелеш эшенә турыдан-туры җитәкчелек иткән Рубин абый үзе оештыра, гомумән ул мәчетне ачу хәленә җиткергәнче күп көч һәм тырышлык сала. Татарстан Республикасының атказанган төзүчесе Рафаил Фәттах улы манараны Яр Чаллыда эшләтә, аны зур техника, краннар белән алып кайтып урнаштыруны оештыра, кирәк чакта техника белән ярдәм итә. Электр һәм җылыту системасы эшен Ринат Фәттах улы үзе башкара, Куйбышев исемендәге хуҗалык рәисе Айрат Акберов төзелеш барышында кирәк булганда даими техника белән ярдәмләшә. Сабантуенда хуҗалык рәисенә авылда мәчет салдыру эшендә ярдәм күрсәткәне һәм эш барышын даими күз уңында тотканы өчен Нуретдиновлар суыткыч бүләк итәләр.

Менә шулай, изгелек беркайчан да югалып калмый.

Мәчет эшчәнлеген биш еллап авыл аксакалы Тәлгать абый Шакиров башкара. Хәзер инде имам вазыйфасында Фирнат Мулланур улы Зарапов.

КӨНТҮГЕШ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

1990–2010 елларда имам-хатыйб Фәизов Наил Фәиз улы.

Көнтүгеш авылында бер мәчет була. Аның төгәл ничәнче гасырда салынганы мәгълүм түгел. Мәчет каршысында мәдрәсә эшли, монда укытучы булып авыл мулласы Суфиян дигән кеше тора. Элек кечкенә булган мәчет 1870 елда зурайтылып, озынлыгы 25 метр чамасы, иңе 7–8 метр чамасы, биек манаралы мәчет була. Манарасы – яшелгә, түбәсен смолага буяп салган булалар.

1880–1885 елларда олы урамда яңа мәдрәсә төзиләр. Анда иң әүвәл – Нури мулла, соңыннан Шаинур исемле мулла укыта. Укучылары арасында 1897–1983 елларда Көнтүгеш авылында яшәгән, авылның тарихын үз куллары белән язып калдырган Солтанша Тимергале улы Садыйков та була.

1917 елда ике иске йортны бергә кушып, яңа мәдрәсә бинасы салына. Монда укытучылар булып Фәйрүз Садыйков һәм Хәсәнша исемле кешеләр эшлиләр.

1939 елда мәчетнең манарасын кисеп төшерәләр, ә 1960 елда мәчетне сүтеп, колхоз идарәсенә әйләндерәләр.

Түбән оч мәчете 1907 елда салына. Ул да 1935 елда сүтелеп, бүрәнәләре мәктәп, клуб биналарына кертелә.

Соңгы елларда Көнтүгеш авылында Фаизов Наил Фаиз улының тырышлыгы белән мәхәллә оештырылды. Ул җомга намазларын һәм имамлык вазыйфасын алып барды.

МАТА АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Мәчете булган авыл халкы
Тәүфыйк-бәхеткә тулыр,
Аллаһыга сыенганнар –
Изге гамәлләр кылыр.
Мәчетле авыл халкы ул
Итәгатьле, шәфкатьле.
Һәр милләт үз телен белеп,
Динен тотарга хаклы.

Мәчетне төзетүче һәм беренче имам-хатыйбы Гафуров Тәлгать Гафурҗан улы.

Авылның беренче мәчете 1930–1958 елларда мәктәп итеп файдаланыла.

Авыл аксакаллары сөйләве буенча, мәчетне Гаделсөрәй һәм Дилмөхәммәт байлар эшләткән. 1958 елда яшен ату сәбәпле, ул янып китә. Бу урында хәзер мәктәп урнашкан.

Авылда мәдрәсә дә була. 1879–1880 елларда Иштирәк авылы кешесе Гыйләҗетдин хәзрәт гаиләсе белән Мата авылына күченеп килә, 1914 елга кадәр дин-мәчет эшләре белән җитәкчелек итә һәм 1880 елда дүрт почмаклы (уртача зурлыктагы өй кадәр) мәдрәсә бинасын салдырта (хәзерге яңа мәчет йортының бакча артында). Акча һәм төзү материаллары белән авыл халкы ярдәм итә.

Авыл картлары Дәүләтбай, Мәүләви, Гыйльмисолтан картлар истәлекләренә караганда, хәзрәтнең авылдашы Бәдертдин исемле укытучы мәдрәсәгә эшкә килә. Аның аягы гарип булганлыктан, шәкертләр кечкенә чанага яки арбага утыртып, авыл буйлап ашка-чәйгә йөртәләр. Хәлфә мәдрәсә эчендә, такта белән бүленеп алынган кечкенә бүлмәдә яши.

Мәдрәсәдә урта хәлле кешеләрнең балалары гына белем ала алган, ярлылар балаларын укыта алмаган. Анда Дәүләтҗан Әминев, Мифтахетдин Кашапов, Йосыф бабай, Дәүләтбай Гайсин, Гайнан Дәүләтҗанов һәм башкалар укый. Бай кешеләр үз балаларын күрше авылларга, зуррак дәрәҗәле мәдрәсәләргә җибәреп укытканнар.

Империалистик сугыш, революция, Гражданнар сугышы һәм аннан соңгы елларда – 1930 елга кадәр авыл халкыннан Сәрвәртдин Гыймадетдинов – мулла, Шәрифҗан Мөхәмәтҗанов мөәзин вазыйфасын үтиләр. Алар дин-мәчет эшләренең иң соңгы вәкилләре, чөнки аннан соң Совет власте мәчетләрне яптыра.

1992 елда авыл халкы үзара киңәшләшеп, мәчет төзү турында сүз кузгата. Һәм бу тәкъдимне «Балтач» совхозының чираттагы



Имам-хатыйб Әдехәм хәзрәт.

җыелышында көн тәртибенә кертергә дигән карарга киләләр. Җыелышта бу мәсьәләне хуплыйлар гына. Мәчет төзү буенча совет сайланып куела. Төзү эшен алып барырга матди яктан әзерлек булмау сәбәпле, авыл буенча йөреп Мөхәммәтнур Әмиров, Карый Солтанов, Рифгать Зариповлар кешеләрдән акча җыялар. Төзелеш эшләре белән Тәлгать Гафуров җитәкчелек итә һәм үзенең бер җиңел машина алырлык акчасын да мәчет төзелешенә бирә. Төзү эшләре барышы «Балтач» совхозы директоры Рафаэль Әхмәтов, Штәнде авыл Советы рәисе Рәшит Вәлиевнең даими күзәтү астында алып барыла.

Күмәк көч һәм зур тырышлык белән 1996 елның 28 июнендә мәчет ачу мәҗлесе оештырыла. Аны ачу тантанасында БДБ илләренең Европа өлеше Диния нәзарәте рәисе, баш мөфти Тәлгать Таҗетдин, Дәүләт Думасы депутаты, якташыбыз Әлфир Шәйхетдинов, Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаров, район хакимияте башлыгы Рәшит Исламов, тирә-як авыллардан да кунаклар катнашты.

Мәчетнең имам-хатыйбы итеп, мәчет төзелеше белән җитәкчелек иткән Тәлгать Гафуров сайланды.

ТҮБӘН КАНСӨЯР АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Хафиз хәзрәт җитәкчелегендә Түбән Кансояр авылында җеназа намазы. 1957 ел.

Казан шәһәрендә яшәгән һәм җаваплы вазыйфада эшләгән, тумышы белән шушы авыл егете Әбелгас Султый улы Солтанов авылларында мәчет булдыру турында сүз күтәрә. Аның бу изге уен ишетү белән колхоз идарәсе җыен җыеп, авыл халкы белән сөйләшә һәм киңәшләшә. Башлангыч класслар укыган мәктәп бинасына реконструкция ясап, мәчет итү турында сүз алып барыла анда. Авыл халкы мондый изге уйны зур теләк белән кабул итә һәм мәчеткә реконструкция ясау эшенә бик теләп катнаша башлый. 15–20 көн эчендә эш төгәлләнә дә. Якташлары Әбелгас Солтанов материаль яктан зур ярдәм күрсәтә. Манарасын калай белән яптырта һәм тышын да йөзләргә булышачагын белдерә.

Әнә шулай кумәк көч белән Аллаһы йортының ишекләре тиз көндә, яки 1999 елның сентябрь аенда ачыла. Аны ачу тантанасы көнне иртәнге якта туктаусыз көзге яңгырлар яуды, шулай да халык күп җыелды. Ни гаҗәп, изге мәҗлесне Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хаҗи Шәйхәйдәров азан укып ачуга, күк йөзендәге болытлар артыннан балкып кояш чыкты. «Аллаһы Тәгалә безнең белән бергә куана бу изге эшкә», – дип юрадылар мөселманнар.

Биредә Татарстан Республикасының күперләр төзетү буенча идарәлекнең генераль директоры Әбелгас Солтанов чыгыш ясап, авылдашларын мәчетле булулары белән ихлас котлады.

– Дөнья мәшәкатьләренә сылтанмый, байлык җыюдан, хәмер эчүдән тукталып, мәңгелек ахирәткә бара торган гамәлләргә дә ихлас булыйк, – диде ул.

Шулай ук Татарстаннан тантанага килгән «Гидромонтаж» акционерлар җәмгыяте директоры Н. Шәйдуллин, «Реал» төзелеш предприятиесе директоры Д. Әхмәтшин, «Новатор»

Солтанов Әбелгас Султый улы.

акционерлар җәмгыяте директоры Ф. Яруллин, юллар төзетү буенча идарәлекнең генераль директоры Р. Закировлар мәчет ачылу уңаеннан котлап, матур һәм кыйммәтле келәмнәр бүләк иттеләр.

Район хакимияте башлыгы Айрат Мәгьзүмов, «Таныл» колхозы рәисе, җирле хакимият башлыгы Ринат Шәйхлиев, Тучыбай урта мәктәбе директоры Фирдәвис Зөлкаровлар чыгыш ясап, изге йорт ачылу белән котладылар һәм бүләкләр тапшырдлар. Мәчеткә мулла, мөәзин сайланып куелды.

Изге йортка сукмаклар суынмасын, дигән теләктә калды һәркем.

Мәчетнең имам-хатыйбы Бари хәзрәт.

ЧИШМӘ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ

Мәчет төзүче Илүс Каһиров.

Мәчетләр төзү кеше күңеленә – нур, авылга ямь өсти.

Чишмә авылында моннан ярты гасыр элек мәчете дә, укымышлы муллалары да булган. Тик балаларны укыту өчен урын булмау сәбәпле, аның манарасын кисеп, мәктәп итеп үзгәрткәннәр. Әмма диннән ваз кичмәгәннәр, дини йолалар башкарылып килгән. Бу турыда авылның өлкән буын кешеләре еш телгә алып сөйли торган булган.

2000 елда хуҗалыкның халык белән үткән бер җыелышында авылда мәчет салу турында сүз кузгатыла.

– Авылга газ ягулыгы килә, бер мәчет кенә төзи алырбыз, җәмәгать, башлыйк бу эшне, – диләр күпләр чыгыш ясап. Җыелышта карар да чыгарыла. Аны тормышка ашыру өчен авылдашлар һәм читтә яшәгән якташлар ярдәме белән бергәләп бура кайтартуда хәстәрлек күрелде. Электән төзелеш бригадиры булып эшләп, хаклы ялга чыккан Фәүзи абый Шәйнуров мәчетне төзү эшен оештырып йөрде. Авыл халкы да нинди генә эше килеп чыкмасын, кире какмадылар, акчалата да зур ярдәм күрсәттеләр.

2004 елның декабрь аенда үткәрелгән мәчет ачу мәҗлесендә чыгыш ясаучылар мәчетне үз исәбенә төзетүче, Уфа шәһәрендә яшәүче якташлары Илүс Каһировка рәхмәт белдерде. Шулай ук төзелеш эшләрендә актив катнашучы Фәүзи, Самат, Рафаэль, Ринат һәм мәчетнең имам-хатыйбы вазифасын башкарачак Ягафәр абыйларга зур рәхмәтләр житкерелде.

Мәчетнең имам-хатыйбы Ягафәр хәзрәт.

Мәчет ачу тантанасына Башкортстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәммәт хәзрәт Нигъмәтулла, Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаровлар зур канәгатьлек белән килделәр. Биредә күрше Борай районы мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рифат Зарипов, Рөстәм хәзрәт Шәйнуров, Борай мәчете имам-хатыйбы һәм мәдрәсә мөгаллиме Илдар Шәрәфиев, дини оешма вәкиле Ринат Рияновлар, тирә-як авыл мәчетләреннән дә хәзрәтләр катнаштылар. Бу дини бәйрәмгә хәтта

Чишмә мәчете шәкертләре.

Мәүлид бәйрәме. 2009 ел.

Мәүлид бәйрәме. 2009 ел.

Күгәрчен районы мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Радиф хәзрәт тә килгән иде. Алар да иман нуры кайтаручы йортның ачылуы сәбәпле, авыл халкының шатлыкларын ихлас уртаклашуларын белдерделәр.

Югары Янактай авыл Советы муниципаль берләшмәсе башлыгы Рәфисә Әхәтова, урындагы ветераннар советы рәисе Мәснәви Гәрәев, мәчетнең имам-хатыйбы Ягафәр Ибраһимов, Илүс Каһировлар ясаган чыгышларда да авыл халкының яшен дә, картын да киләчәктә тик изге гамәлләр, уйлар белән яшәргә, күңел пакьлеге, динне ихтирам итәргә чакыру яңгырады.

ШӘВЪЯДЫ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Хәбипов Әсхәт Мирхәйдәр улы.

Шәвъяды авылына 1873 елда нигез салына. 1893 елда мәчет төзү эше башлана һәм 1897 елда төзелеп бетә. Ул елларда Борай районы Тазлар авылыннан Шәмсетдин дигән хәзрәт килеп, дин эшләре белән җитәкчелек иткән.

1930 елларда дини эшчәнлекне эзәрлекләү башлана, шул ук елда мәчет манарасын кисеп төшерәләр һәм бина мәктәп итеп файдаланыла.

2004 елның гыйнварь аенда авыл халкының тәкъдимен һәм сорауларын исәпкә алып, мәчет төзү турында җыелыш оештырыла, бу тәкъдимне халык хуплап каршы ала. Шул ук елның март аенда төзү эшләре башлана: материал әзерләнә, бура бурала һәм фундамент салына.

Мәчетне төзүдә авыл халкы булдыра алган кадәр ярдәм итә, «Искра» кооперативы рәисе Хабипов Ф. Ә. , Фәхразов Ф., Әхмәдуллин Р., Гайсина Р., Садриева А., Солтаншин А., Хәбипов А., Рамазанова Р. матди яктан ярдәм күрсәттеләр. Эшне дәвам итүдә хезмәт ветераны Ә.Х. Хәбиповның өлеше зур.

Мәчет төзүчеләр.

ЗИЛӘЗЕКҮЛ АВЫЛЫ МӘЧЕТЕ



Мәчет төзүче Хәлимулла Галиәхмәт улы Хаҗиев.

Зиләзекүл авылы тарихына күз салыйк. Авыл 1803–1911 елларда шундый исемле күл буенда барлыкка килә. Анда Чуртанлыкүл авылыннан чыккан халык килеп урнаша. Шулай ук Мишкә районы Бабай авылы халкы да бирегә күченеп килә (1825), Зиләзекүл авылы зурая төшә.

VII ревизия мәгълүматлары буенча биредә 114 кеше, VIII ревизия мәгълүматлары буенча 224 кеше саны рәсмиләштерелгән. 1905 елда исә авылда – 134 йорт, 727 кеше, 1920 елда 152 йорт, 736 кеше саны исәпкә алынган. Элек-электән бу төбәк халкы иман кануннары белән яшәргә омтылган. Авылда ике мәчет булган. Берсе күл янындарак, икенчесе биек калкулыкта урнашкан. Ул күлнең көньягында ерактан күңелне әсир итәрлек итеп күренеп торган. 1933 елда мәчет бинасын мәктәп итеп куллана башлыйлар. 1934 елда мәчеттә янгын чыга, аның манарасы күлгә авып төшә. Мәчет бинасы янганнан соң, авыл халкы аерым өйләргә йөреп укып, дин кануннары буенча яшәргә тырыша. Бөек Ватан сугышы чорында намаз укып көн итәләр.

Мәчет ачу тантанасы. 1996 ел.

Мәчетнең имамнары Шәфкать Әхәтов, Кави Гаязов һәм Мәгъданур Мәрданов.

Зиләзекүллеләр дин әһелләре Зариф хәзрәтне, Әбелкарам хәзрәтне, аның улы Мөхәммәтһади һәм мөәзиннәр Талип, Сәгъди, Зариф һәм башкаларны җылы хатирәләрендә яңарта. Бигрәк тә Галихан Хаҗимәрдәнов тырышлыгын билгеләү урынлы. Яшь ярым вакытында сукыр калганга, ул дөнья яктысын белмәгән. Ырынбур өлкәсе Каргалы авылында, Уфа, Казан шәһәрләрендә белем алган. Аны халык «сукыр суфый абзый Галихан хәзрәт» дип йөрткән. 17 ел буена белемен арттырган хәзрәт изге Коръәнне яттан белгән, намазын калдырмаган.

Авыл җирлегендә өченче мәчет төзелә.

Зиләзекүл авылында яңа мәчет 1996 елда ачыла.

Бирегә шулай ук бу изге эшне башлап йөрүче булып якташлары Хәлимулла Галиәхмәт улы Хаҗиев була.

Хәлимулла читтә яшәсә дә, туган авылын, якташларын онытмый, алар хакына кулыннан килгәннәрнең барын да эшли. Иң элек ул авыл зиратына өй салдыра, рәшәткәләрен буятырга кирәк-ярак хәстәрләү өчен акча бирә. Аның матур уе моның белән генә чикләнми, авылга мәчет салдыру нияте белән йөри. Һәм бу уен тормышка ашыра ул. Барлык чыгымнарны үзе күтәреп, өр-яңа мәчет бинасы салдыра.

– Мәчетле авылда халык та тәүфыйклы булыр, иншааллаһ, – диде Хәлимулла Хаҗиев мәчет ачу тантанасында авылдашларына һәм килгән кунакларга. – Бу исә дин юлына басуда беренче адым булып тора. Аллаһы йорты буш тормасын, бүгенге кебек һәрвакытта да халык белән шыгрым булсын...

Әйе, кыйммәтлелек дип, төзелешләрдән баш тартырга ярамый. Ә бит әхлакый кыйммәтләребезне кайтаруны заман үзе таләп итә. Кешеләр арасында агарту-аңлату эшләре сүнде, һәм аннан мәдәният учаклары да читләште. Мондый шартларда халык арасында әхлак тәрбиясен көчәйтүдә, күңелләргә мәрхәмәтлелек, шәфкатьлелек орлыклары чәчүдә – дин бердәнбер йогынтылы көч һәм чара ул.

Бәйтулла ачу тантанасында БР Корылтаеның Законнар чыгару палатасы депутаты Фәүхетдин Фатхуллин, район хакимияте

башлыгы Айрат Мәгъзүмов, Башкортстан Диния нәзарәте рәисе, мөфти Нурмөхәммәт хәзрәт Нигъмәтулла, «Иман» тапшыруын алып баручы журналист Сәләхетдин хаҗи Сукбаев, Иске Балтач мөхтәсибәте имам-мөхтәсибе Рәфис хәзрәт Шәйхәйдаровлар катнашты.

Мулла итеп Шәфкать Әхәт улы Әхәтов билгеләнде. Мөселманнар соравы буенча, күңеле белән дингә тартылган кешене хуҗалык исәбенә укырга җибәрергә кирәк, дигән фикергә килделәр бу көнне.

Шунысы куанычлы, изге эшкә ата-бабаларыбызның борынгыдан килгән ислам дине йолаларын тергезүгә районыбыз җитәкчелеге дә уңай караштa тора. Бу тантанада катнашучылар изге эштә, изге уйда булучыларны, иншаллаһ, Аллаһы Тәгалә ярдәменнән ташламас дигән, теләктә калдылар.

Вакыт әкрен генә уза, берничә еллар Шәфкать Әхәтов, Рәҗәп Камалов, Кави Гаязов имам вазифаларын үтәп, дөньядан уздылар. Бүгенге көндә бу эшне Мәрданов Мәгъдәнур Галимхан улы дәвам итә.

ТУТАГАЧ АВЫЛЫНА ИМАН НУРЫН ТАРАТУЧЫЛАР

Зараев Хәлфәт Карам улы һәм Гатауллин Тимергәле Гатаулла улы.

Тутагач авылы Тутагач исемле күл буенда XIX гасырның икенче яртысында барлыкка килә. 1906 елда анда 76 йортта 409 кеше яшәве, 1920 елда 104 йортта 612 кеше яшәве теркәлә.

Авыл халкы иман юлына тартылуы белән билгеле. Тутагач авылы мәчетендә имам, мөәзиннәр иман нурын таратуда бихисап көч салган. Алар тәкъвалык белән аерылып торганнар, шуңа да тутагачлылар аларның һәммәсен җылы сүз белән искә ала. Авыл тарихында үз исемнәрен язган шәхесләр:

1. Кашафетдинов Әүгать (указлы мулла).
2. Бадегитдинов Фәкетдин Бадегитдин улы (мөәзин), (1879–1966).
3. Садертдинов Фәрхетдин (мулла вазыйфасында).
4. Фәрхетдинов Әсхәт (мулла вазыйфасында).
5. Кашапов Малик Кашап улы (1904–1991).
6. Хиҗәпов Миңнулла Хиҗабетдин улы (бер кулын югалткан ветеран), (1899–1984).
7. Сафиев Кашафетдин Сафетдин улы.
8. Зекрин Касыйм (1920–2009).
9. Гатауллин Тимергале Гатаулла улы.
10. Зараев Халфәт Карам улы.

Хәлфәт Карам улы Екатеринбургның Рахман мәдрәсәсендә дини белем ала. 2007 елда Тутагач авылында мәчет төзетү өчен урын хәстәрли. 2008 елда төзелеш эшләре җәелдерелә. 2010 елда кирпечтән мәчет бинасы төзетү эше җанлы бара. Тутагач авылына мәчет азан тавышы белән иман нурын таратыр дигән ышаныч бар.

«Салават җыены»нда иртәнге намаз. 2006 ел.



Чуртанлыкүл авылы мәчете. Шайхлисламов А.Ә. сурәте.



Яңа Балтач авылы мәчете.



Тутагач авылы мәчете фотосурәте.

Норкә авылы мәчете фотосурәте.



Сәйтәк авылы мәчете фотосурәте.



Тимкә авылы мәчете. Аскарова Ф. М. фотосурәте.



Түбән Кансәяр авылы мәчете.

Тимкә авылы мәчете. Ахкямов Гафиф фотосурәте.

Тушкыр авыл мәчете. Вахитов Х. А. фотосурәте.

Мата авылы мәчете фотосурәте.

Мәнәгәз авылы мәчете. Файрушин Д. З. сурәте.

Чурапан авылы мәчете. Хайдаров И. Ф. сурәте.

Иске Яхшый авылы мәчете. Талипов Г.М. фотосурәте.

БЛАГОДАРСТВЕННОЕ ПИСЬМО

Уважаемый Рафис Муллатдарович!

От всей души благодарю Вас за активное участие в избирательной кампании по выборам Президента Республики Башкортостан, за Вашу гражданскую позицию, заботу о будущем родной республики и всей России.

Президент
Республики Башкортостан М. Рахимов

Уфа, декабрь 2003 года.

ГРАМОТА

Настоящей Почетной грамотой
награждается
Шайхайдаров Рафис Муллаатдарович
директор муниципального
учреждения культуры и искусства
"Музей Габдуллы Галиева (Батырши)"
Балтачевского района
Республики Башкортостан
за активную пропоганду истинной
роли просветителя XVIII века
Габдуллы Галиева (Батырши)
в истории России и Башкортостана.

Начальник отдела культуры
АМР Балтачевский район: Г.К.Сарвартдинов

11 октября 2006 г.

Благодарность

От имени Президиума Балтачевского районного Совета выражается **ШАЙХАЙДАРОВУ РАФИСУ МУЛЛАТДАРОВИЧУ** – депутату от избирательного округа № 8 за активное участие в работе Балтачевского районного Совета двадцать третьего созыва.

Желаем вам крепкого здоровья, счастья и дальнейших успехов в работе.

Председатель районного Совета **А.М.Магзумов**

февраль, 2004г.

محمد
الله جل جلاله
ДУХОВНОЕ УПРАВЛЕНИЕ МУСУЛЬМАН РЕСПУБЛИКИ БАШКОРТОСТАН
النظارة الدينية لمسلمي جمهورية باشقرتستان
HOLY MOSLEM ADMINISTRATION OF THE REPUBLIC OF BASHKORTOSTAN
بسم الله الرحمن الرحيم
Шаһәҙәтнамә
Башҡортостан диниә назараты халҡыбыҙ мәнфәғәттәрен ҡайғыртып, ҡылған игелекле ғәмәлдәре, бигерәк тә: ҡөрьән хафиз, себер юлы ахуны, дин ғалимы, тарихсы, философ, әҙип, энциклопедик шәхес, XVIII быуат мәғрифәтсеһе Габдулла Ғалиев (Батырша) мираҫын һаҡлап ҡалыуға һәм музейын төҙөүгә индергән бинниһая тырышлығы өсөн
Рәфис Муллағәтдәр хәҙрәттәренә
"Шәфәғәт эйәһе"
исеме бирелә. Ошо хаҡтағы шаһәҙәтнамә Габдулла Ғалиев (Батырша) музейына тапшырыла.
Башҡортостан Республикаһы Мөселмандарының Диниә Назараты рәйесе, Мөфтөй
Нурмөхәмәт Нигмәтулла

ПОЧЕТ ГРАМОТАҺЫ
ПОЧЕТНАЯ ГРАМОТА
НАГРАЖДАЕТСЯ
Администрацией муниципального района Балтачевский район Республики Башкортостан
Шайхайдаров Рафис хажи Муллаатдарович
- имам-мухтасиб Балтачевского мухтасибата имам-хатиб Балтачевской соборной мечети им. Габдуллы Галиева «Батырши»,
за сохранение, пропаганду и развитие историко-культурного наследия народов родного края
Глава Администрации муниципального района
Р.А. Галлямов

МЕДАЛЬ
„В ПАМЯТЬ 1000-ЛЕТИЯ КАЗАНИ"
№ 047965
ШАЙХАЙДАРОВ
(фамилия)
Рафис
(имя)
Муллаатдарович
(отчество)
Указом Президента Российской Федерации от 30 июня 2005 г. награжден(а) медалью
„В ПАМЯТЬ 1000-ЛЕТИЯ КАЗАНИ"
От имени Президента Российской Федерации медаль вручена
09 декабря 2008 г.
Президент Республики Татарстан
(должность,
М.Ш. Шаймиев
подпись лица, вручившего медаль)



Башкортстан, Татарстан, Казахстан вә Украина җөмһүриятләрендәге һәм РСФСРның башка вәлият вә крайларындагы мөселманнарның мәркәз Диния нәзарәтеннән.

Шаһәдәтнамә

Бу шаһәдәтнамә Башкортстан җөмһүрияте Иске Балтач районы Көмьязы авылыннан Рәхимҗан Гайнетдиновка бирелде. Шул хосуста Башкортстан җөмһүрияте Иске Балтач районы Көмьязы авылының беренче мәхәлләсендәге мөселманнарның дини хаҗәтләрен башкаручыга мохтаҗ булдыкларыннан мәхәллә халкының иттифак белән сайлауларына күрә мәркәз Диния нәзарәте үзенең ошбу 1934 елның 7 февралендә булган карары белән Рәхимҗан ибне Гайнетдингә мәзкүр Көмьязы авылы 1 мәхәлләсендә дини луазим башкарырга: 5 вакыт намаз, җомга вә гает намазларына укырга вә башка һәртөрле дини мерәсемнәрне үтәп торырга рөхсәт итә вә шул хакта аңа ошбу шаһәдәтнамә биреләдер.

Дини нәзарәтнең рәис мөфти: Р. ибн Фәхретдин
Казый: Зиаэддин Камали

ЭЧТӘЛЕК

Балтач мәчетләре....6
Иске Балтач җәмигъ мәчете....14
Богдан авылы мәчете....21
Яңа Ямурза авылы мәчете....23
Текән авылы мәчете....27
Көндәшле авылы мәчете....31
Чуртанлыкүл авылы мәчете....35
Илекәй авылы мәчете....37
«Мөхәмммәтзыя» мәчете....39
Иске Тушкыр авылы мәчете....42
Мишәр авылы мәчете....46
Сәйтәк авылы мәчетләре....49
Иске Яхшый авылы мәчетләре....54
Штәнде авылы мәчете....58
Иске Янбай авылы мәчете....60
Түбән Сикияз авылы мәчете....63
«Нур» мәчете....68
Югары Карыш авылы мәчете....70
«Нәвилә» мәчете....75
«Яңа тормыш» мәчете....81
Бигелде авылы мәчете....85
«Хәнифә» мәчете....89
Көнтүгеш авылы мәчете....92
Мата авылы мәчете....93
Түбән Кансөяр авылы мәчете....96
Чишмә авылы мәчете....99
Шәвъяды авылы мәчете....103
Зиләзекүл авылы мәчете....105
Тутагач авылына иман нурын таратучылар....109
Кушымта....111

ББК 86.38
Ш-91

Шәйхәйдәров Р.
Ш-91 Балтач мәчетләре – Казан. – «Идел-Пресс», 2010. – 120 бит.

ISBN 978-5-85247-412-4
© «Идел-Пресс» бизәлеше, 2010

Техник редакторы *С. Кинтас*
Компьютерда биткә салучысы *Т. Маклакова*
Дизайн *В. Чекалкина*
Корректорлары *Г. Дәүләтҗанова, Г. Замдиханова*

Кәгазь форматы 60×84 1/8.
Тиражы 1000 данә. Заказ Н-1224.

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.

Шәйхәйдаров Рәфис Маллагатдәр улы 1954 елның 1 августында Свердловск өлкәсенең Югары Пышма шәһәрендә туган. Югары Карыш урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Совет Армиясе сафында хезмәт итә, өлкән сержант. Хезмәт юлын 1968 елда Балтач районының Калинин исемендәге кумәк хуҗалыгында комбайнер ярдәмчесе булып башлый. Дуван авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлый. Ферма мөдире һәм озак еллар кумәк хуҗалыкның баш зоотехнигы булып эшли. 1991–1992 елларда Үзәк Диния нәзарәте каршындагы Ризаетдин Фәхретдин исемендәге, 1994–1999 елларда Казан «Мөхәммәдия» мәдрәсәләрен тәмамлый. 1993 елның май аеннан Иске Балтач мөхтәсибәтенең имам-мөхтәсибе, Балтач мәчетенең имам-хатыйбы. Нәсел шәҗәрәсе XVIII гасыр мәгърифәтчесе, дин әһеле Габдулла Галиев Батыршага барып тоташа. Батырша китапханәсен саклаучы һәм йорт-музее директоры. «Казанның 1000 еллыгына» медале иясе.

ISBN 978-5-85247-412-4